РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ
ФИЛОЛОГИЯ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ
ТӘРҖЕМӘ БЕЛЕМЕ ҺӘМ МӘДӘНИЯТАРА БАГЛАНЫШЛАР БҮЛЕГЕ
ТӘРҖЕМӘ ТЕОРИЯСЕ ҺӘМ СӨЙЛӘМ КОММУНИКАЦИЯСЕ КАФЕДРАСЫ

Р.Р.СӘЛАХОВА

# ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ТАБИГАТЬ ДӨНЬЯСЫ

Казан 2012

УДК 811.512.145`36
ББК 81.2Тат-2

Бәяләүче – педагогика фәннәре кандидаты
доцент Фәтхуллова К.С.

**Сәлахова Р.Р.**
Татар теле дәресләрендә табигать дөньясы: “Биология” белгечлеген үзләштерүче студентлар өчен укыту кулланмасы. – Казан, 2012. – 56 б.

Югары һөнәри белем бирү уку йортларының төп максаты - икетеллелек һәм күптеллелеллек шартларында эшләргә сәләтле иң югары дәрәҗәдәге белгечләр әзерләп чыгару. Хезмәт шул максатны күздә тотып төзелде. Ул “биология” белгечлеген үзләштерүче студентларга кулланма буларак тәкъдим ителә.

Татар теле дәресләрендә укучыларда аралашу осталыгы булдырылуга, аның ярдәмендә һөнәри һәм гомуммәдәни әһәмиятле мәгълүмат алу теләген уяту төп бурычлардан санала. Аралашу өчен сайлап алынган теманың студентның булачак һөнәре белән бәйле булуы бик мөһим. Кулланмадагы ботаника, зоология өлкәләренә караган текстлар аша студентлар татар теленең үзенчәлекләрен үзләштерә һәм татар халык авыз иҗаты үрнәкләре белән дә таныша алалар.

Әлеге хезмәт һөнәри белем бирү уку йортларында “биология” белгечлеген үзләштергән белгечләргә икетеллелек шартларында үзе сайлаган өлкәдә төпле, иҗади эшләвенә ирешүгә ярдәм итәр дигән ышаныч бар.

Хезмәт татар теле һәм биология белән кызыксынган һәр кешегә, беренче чиратта, татар теле укытучыларына, “биология” белгечлеген үзләштерүче студентларга атап чыгарыла.

© Сәлахова Р.Р., 2012
©Югары һөнәри белем бирү
дәүләт мәгариф учреждениесе
“Филология һәм сәнгать институты”, 2012

# К Е Р Е Ш

Телгә өйрәнү – ул тел турында кагыйдәләр өйрәнү генә түгел. Телгә өйрәтү үз эченә сөйләм эшчәнлегенең һәрбер төренә - сөйләшүгә, тыңлап аңлауга, укуга, язуга өйрәтүне ала. Ә инде сөйләм эшчәнлегенең әлеге төрләренә карата сайланган тел материалының белгечлек белән бәйле булуы, беренчедән, телгә карата кызыксынуны арттырса, икенчедән, студентка үз һөнәре буенча алган белемнәрен тагын да баету мөмкинлеге тудыра. Китап “Татар теле дәресләрендә табигать дөньясы” дип юкка гына аталмый, биредә “Биология” белгечлеген үзләштерүче студентларга тәкъдим ителә торган текстлар биология фәненең төп тармаклары булган ботаника, зоология өлкәләренә карый.

Телне өйрәнү – билгеле бер күләмдәге тел материалын, ягъни фонетик, лексик, грамматик минимумнарны үзләштерү дигән сүз. Укучы билгеле бер күләмдә тел материалын өйрәнергә һәм истә калдырырга тиеш була. Әлеге хезмәт “Татар теленең аваз төзелеше”, “Татар телендә сүз төзелеше”, “Татар телендә сүзнең лексик мәгънәләре” кебек темаларны үзләштерү белән бергә, үсемлекләр, кошлар, имезүчеләр турында кызыклы мәгълүмат җиткерә.

Терминология – шактый катлаулы өлкә. Кайсы гына телне алма, әлеге телдә төрле тармакларга караган терминнар ясалып тора, искергәннәре югала, кулланылыштан төшеп кала. Теге яисә бу телдәге терминнар системасының эшләнү, эшкәртелү дәрәҗәсе гомуми тел үсеше турында фикер булдыра. Биология фәннәре системасына караган күп санлы терминнарның ике телдә дә өйрәнү студентларга фәнни планда гына түгел, гомумән, дөньяны танып белү юнәлешендә кызыклы нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә. Кулланмада кайбер биологик атамаларның килеп чыгышы турындагы мәгълүматлар, биологик терминнар (үсемлек, кош-корт, имезүчеләр атамалары), татарча-русча сүзлекчә шул максаттан чыгып тәкъдим ителә.

Телне өйрәнү барышында әлеге телдә сөйләшүче җирле халыкның милли мәдәнияте һәм сәнгатен өйрәнүгә дә зур урын бирелергә тиеш. Милли мәдәниятнең иң югары казанышын халык авыз иҗаты әсәрләре тәшкил итә. Телгә өйрәтүгә караган методик хезмәтләрдә аларга игътибар җитенкерәп бетми кебек. Моңа кадәр бары тик татар теленең грамматик нигезләрен генә үзләштергән һәм монологлар төзеп сөйләргә өйрәнгән укучыларны татар сүз сәнгатенең асыл мәгънәсенә төшендерү - төп бурычларыбызның берсе. “Биология” белгечлеген үзләштерүче студентарны халык авыз иҗатының үсемлекләр, кош-кортлар, киек-җанварлар белән бәйле булган күптөрле жанрлары (мәкаль-әйтемнәр, легенда-риваятьләр, юрамыш-сынамышлар, табышмаклар һ.б.) белән таныштыру татар теленә һәм аның халкына булган хөрмәт хисләрен тагын да арттырыр дип ышанып калабыз.

## 1. ҮСЕМЛЕКЛӘР ДӨНЬЯСЫ. МИР РАСТЕНИЙ

## Татар теленең аваз төзелеше

### §1. Татар язуы тарихы

**Укыгыз һәм истә калдырыгыз!**

Һәр телнең үзенә хас авазлар, хәрефләр системасы булган кебек, татар теленең дә үзенә хас булган үзенчәлекле авазлары, хәрефләре һәм аларга карата кулланыла торган законнар системасы бар.

Безнең ерак бабаларыбыз – борынгы болгарлар VII-VIII гасырларда Урта Идел һәм Кама буйларына күчеп утырганда ук инде аларның үзенчәлекле язулары – үз алфавитлары була. Бу алфавит фәнни әдәбиятта төрки рун язуы дип йөртелә. Рун язуы (run сүзе борынгы Скандинавия халыкларында “серле” дигән мәгънәгә туры килә) – төрки телләрнең фонетик-морфологик төзелешенә яхшы ук җайлаштырылган язу системасы. Көнчыгыш илләре (фарсылар, гарәпләр һ.б.) белән фән, мәдәни, икътисади мөнәсәбәтләргә керү нәтиҗәсендә X йөз башларында рун язуы гарәп язуы системасы белән алмаштырылган. Гарәп язуы белән бергә уйгур язуы да кулланылган. Ислам дине рәсми төстә кабул ителгәч (922 ел), гарәп графикасы гына калган. 28 хәрефле алфавиттагы билгеләрнең егерме бише тартыкны, өчесе сузык авазларны белдергән. Хәреф өстенә яисә астына куелган өстәмә хәрәкәләр ярдәмендә кыска сузыклар күрсәтелгән. Бер үк хәреф берничә авазны белдергәнлектән, болгар чорында төрки сүзләрен язуда төгәлрәк чагылдыру юлларын эзләгәннәр. Урта имла, яңа имла, хәреф реформасы дип аталган чаралар кирәкле хәрефләрне булдыру, кирәксезләрен чыгарып ташлау, орфографияне тәртипкә салу, хәрефләрнең тышкы күренешен төзәтү кебек гамәлләрне үз эченә алган.

Гарәп алфавитының төрки һәм иран телләре өчен яраксыз булуы, аны башка алфавит белән алыштыру зарурлыгын китереп чыгарган һәм төрки халыклар, шул исәптән татарлар да, латин графикасына күчәләр. 1927 елда латин графикасы татар теленең рәсми алфавиты дип игълан ителгән. Барлык мәктәп, матбугат һәм нәшрият 1930 елның 1 январена тулысынча яңалифкә күчеп беткән. Яңалиф – “яңа хәреф” (“әлиф” – гарәп графикасындагы беренче хәреф). Хәзерге татар язуы рус галфавитына нигезләнгән, ул 1939 елдан бирле дәвам итә.

1. Түбәндәге сорауларга җаваплар языгыз:

а) VII-VIII гасырлардан X гасырга кадәр нинди язу кулланылган?

ә)Уйгур язуы кайчан кулланылган?

б) Гарәп язуын гына куллана башлау нинди тарихи вакыйгага бәйле?

в) Гарәп графикасын нинди язу алмаштырган? Сәбәпләрен аңлатыгыз.

г) Хәзер татарлар нинди графикага нигезләнеп язалар һәм ул ничәнче елдан гамәлдә?

### §2.Сузык авазлар системасы

**Укыгыз һәм истә калдырыгыз!**

Татар алфавитында барлыгы 39 хәреф бар. Ул рус алфавитыннан татар теленә генә хас булган **ә, ө, ү, ж, ң, һ** хәрефләре белән аерыла.

А **Ә** Б В Г Д Е Һ Ж **Җ** З И Й К Л М Н **ң** О **Ө** П Р С Т У **Ү** Ф Х **Һ** Ц Ч. Ш.Щ ъ Ы ь Э Ю Я

Татар телендә 9 сузык аваз бар: **а, ә, о, ө, ы, э, у, ү, и**

Телнең горизанталь хәрәкәтенә карап, татар сузыкларын алгы(нечкә), арткы (калын) рәт сузыкларга бүләләр: калын сузыклар(арткы рәт): **а, о, у, ы**

нечкә сузыклар(алгы рәт): **ә, ө, ү, э, и**

Сузыкларның калынлыкта яки нечкәлектә бер-берсенә ярашуы **сингармонизм** законын тәшкил итә. Татар телендә (гомумән , төрки телләрдә) сүзләрдә сузыклар бер рәтнеке генә булырга тиеш, кушымча ялганса да, сүз я нечкә, я калын гына булып кала: **у**р**а**м-н**а**р-г**а**, **ү**лән-нәр-дән. Сузыкларның шул рәвешле ярашуы **рәт гармониясе** дип атала. Рәт гармониясе башка телләрдән кергән алынмаларда, кушма сүзләрдә һәм татар теленең кайбер искәрмә сүзләрендә сакланмый: *тарих, аудитория, суүсем, көнбатыш, миңа, сиңа, зәңгәрсу* һ.б.

Сингармонизмның икенче төре ирен гармониясе сүзнең беренче иҗегендәге **о,ө** авазларының үзләреннән соң килгән **ы, э** авазларын иренләштерүдән гыйбарәт: *козгын, бөркет*. Икенче иҗектә о, ө авазлары ишетелсә дә, язуда чагылыш табарга тиеш түгел. Нәтиҗәдә, татар телендә икенче, өченче һ.б. иҗекләрдә о, ө хәрефләре язылмый. Кайбер кушма сүзләрдә генә бу авазларны икенче иҗектә очратырга мөмкин: *төнб**о**ек, чебенк**о**ш.*

Сузыкларны төркемләгәндә, аларның монофтонгларга һәм дифтонгларга бүленүенә игътибар итәләр. Бер иҗектә бер сузык булса, монофтонг була. Күпчелек сузык авазлар – монофтонглар. Бер иҗектә ике сузык аваз булса, дифтонг була. Татар телендә бер иҗектә ике тулы сузык очрамый, димәк, чын дифтонглар юк. Ләкин татар телендә ярымтартык ярымсузык й, w авазлары бар. Бу авазлар һәрвакыт тулы хокуклы сузык алдыннан яки аннан соң киләләр. Шулай итеп, бер иҗектә бер тулы сузык, икенчесе ярымсузык булганга күрә, аларны ялган яки ярымдифтонглар дип атыйлар. Әгәр ярымсузык аваз тулы сузыкның алдыннан килсә, аларны **күтәрелмә ярымдифтонглар** дип атыйлар: ябалак [**йа**-ба-лак], суер[су- **йы**р], юлбарыс[**йул**-ба-рыс], кавын [ка-**wы**н]. Киресенчә булса, ягъни ярымсузык тулы сузыктан соң килсә, мондыйлары **төшерелмә ярымдифтонглар** булалар: ут-к**ой**-рык, тур-г**ай,** ту-т**ый** кош һ.б.

**2. Биремнәр.**

1. Текстны укыгыз һәм тәрҗемә итегез.
2. Калын сузыклардан гына торган сүзләрне беренче баганага, нечкә сузыклардан торганнарын икенче баганага, ирен гармониясенә буйсынган сүзләрне өченче баганага язып төшегез.
3. Текстан **е** хәрефе иҗек башында килгән сүзләрне беренче баганага, иҗек уртасында яки ахырында килгән сүзләрне икенче баганага язып төшегез.
4. Тексттагы сүзләрдән алфавитның һәр хәрефенә мисаллар языгыз. М-н: **а**прель, **ә**ле һ.б.

Каен – куе ябалдашы өскә таба киңәеп үсә торган төз агач. Ул кайвакыт кояшлы аланда ялгыз үсә, ләкин гадәттә, ул урман хасил итә. Каен апрель ахырларында яисә майның беренче көннәрендә чикләвек куаклыгы һәм талдан соң чәчәк ата.

Каен орлыгы җил белән бик тиз тарала. Киселгән урманның әле башка агачлар үсә алмаган җирендә дә каен бик тиз үсеп китә. Чирек гасыр эчендә, аеруча дымлы туфракта, ул биш катлы йорт биеклегенә җитә. Каен агачы җәйге җылы көннәрне шул дымлы туфрактан тәүлегенә кырыгар чиләк су ала.

Каенның бөтен өлеше дә эшкә ярый. Бөреләреннән дару әзерлиләр, ботаклары себерке ясауга китә. Тузыннан – ул кәгазь калынлыгыдай юка катламнарга аерыла – халык осталары гөмбә һәм җиләк җыю өчен тырыс ясыйлар. Каен агачыннан фанер, җиһаз эшлиләр, скипидар, агач спирты, серкә алалар.

**ботак – ветвь, ветка, сук, сучок** **туз - береста**
**бөре - почка** **туфрак - почва**
**орлык – семя, семена** **тырыс - кузовок из бересты**
**серкә – пыльца** **чикләвек агачы - орешник**
**тал - ива** **ябалдаш – крона**

**3. Биремнәр.**

1. Текстны укыгыз, тәрҗемә итегез һәм эчтәлеген сөйләргә әзерләнегез.
2. Рәт гармониясенә буйсынмаган сүзләрне язып алыгыз һәм сәбәбен аңлатыгыз.
3. Текст эченнән ялган дифтонгларның ике төренә дә бишәр мисал язып алыгыз.

**Артыш** – мәңге яшел һәм ылыслы куак-агач, кипарисчалар семьялыгына карый, ылыслы урманнарда төркем-төркем булып үсә. Артыш – озын гомерле үсемлек – 300 ел яшәгәннәрен очратырга мөмкин, Тянь-Шань таулары урманнарында 500 еллыклары бар. Аның күркәләре, чәчәк атканнан соң, икенче елның көзенә өлгерә. Алар эфир маена, шикәр, сумала, төрле кислота һәм башка матдәләргә бай. Аның җимешләре төрле сырхауга дәва буларак файдалы, азык сәнагатендә кулланыла.

Артышның тагын бер өстенлеге бар. Ул һавага фитонцидлар бүлеп чыгара, ә алар кеше өчен бик файдалы. Әйе, күмәкләшеп үсә торган бу куаклар – табигатьнең саф һава лабораториясе. Бер гектар мәйданда үсеп утырган шундый хәзинә тәүлек буена 30 килограмм файдалы матдә бүлеп чыгара һәм тирә-юньне сафландыра. Бу исә зур бер шәһәрне зарарлы бактерияләрдән арындырырга җитәр иде. Шуңа күрә артышны кала бакчаларында һәм газоннарында, авыл бакчаларында үстереп карасак, бик тә файдалы эш башкарыр идек.

**азык сәнагате – пищевая промышленность** **сырхау - больной**
**арындырырга - избавлять, освобождать** **күркә - шишка**
**зарарлы матдәләр – вредные вещества** **ылыслы урман – хвойный лес**

## §3. Тартык авазлар системасы

**Укыгыз һәм истә калдырыгыз!**

Татар теленең үзенчәлекле тартык авазлары: w , гъ, җ, къ, ң, һ, ч
яңгырау тартыклар: б,в,г.д,ж,җ,з, (сонорлар) й,л,м,н,р,ң, w
саңгырау тартыклар:п,ф,к,т,ш,ч,с, х,һ, ц, щ, хәмзә

Татар телендә кулланылган бөтен тартык авазларның да хәрефләре юк. Язуда аларны татар теленең алфавитында булган башка хәрефләр белән алыштырырыга туры килә. Мәсәлән, хәмзә гарәп алынмаларында яки ымлыкларда гына очрый торган аваз. Әгәр ул иҗек ахырында килсә, язуда аны э хәрефе белән билгелиләр: *тә**э**-мин, ма**э**-май*. Әгәр хәмзә иҗек башында килсә, аны сүзнең беренче иҗегенең калын яки нечкә булуына карап, ъ яки ь хәрефләре белән күрсәтәләр: *кор-**ъ**ән, мәс-**ь**ә-лә* h.б.

Къ, гъ авазларын язуда к,г хәрефләре белән билгелиләр, алар калын сузыклар янәшәсендә кулланылалар: *кабак, кузгалак* h.б.

W авазының иҗек башында килүен в хәрефе белән билгелиләр: *кыр-га-**в**ыл (фазан), **в**а-рис бы-зыл-да-**в**ык (жужелица-наследница),* иҗек ахырында килгәндә, иҗекнең калын яки нечкә булуына карап, у, ү хәрефләре кулланыла: *саң-гы-ра**у** күке (кукушка глухая), сер-кә-лә**ү**-че-ләр (опылители).*

**4. Биремнәр.**

1. Текстның эчтәлеге белән танышыгыз һәм бер кузаклы үсемлек турында монолог әзерләгез.
2. Калын к авазы кергән сүзләрне беренче баганага, нечкә к авазы кергән сүзләрне икенче баганага язып төшегез. Беренче баганага кергән өч сүз белән җөмләләр төзегез.
3. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрне иҗекләргә бүлегез, иҗек төрләрен билгеләгез.
4. Түбәндәге җөмләләрнең текст эчтәлеге белән туры килгәннәрен дәфтәрләрегезгә язып алыгыз, аларга сораулар куеп карагыз:

*Терлек азыгы өчен ногыт борчагы, ясмык, соя, борчак игәләр. Борчак, соя, ногыт борчагы, ясмыкны кешеләр ашый. Кузаклы культураларны гадәттә көзен чәчәләр. Кузаклыларда аксым бик күп була. Кузаклы үсемлекләр игенчелек өчен бик зарарлы. Кузаклыларның тамырында бүлбеләрдә һавадагы азотны үзләштерә торган бактерияләр бар. Кузаклы культураларның уңышы бик начар була. Бодай һәм кукуруз өчен азот бик файдалы.*

Кешеләр кузаклы үсемлекләрне азык итеп бик күптәннән куллана. Хәзер басуларда, яшелчә бакчаларында кузаклы культуралар – борчак, **ногыт** борчагы, соя, **ясмык** үстерәләр. Аларны кешеләр ашый. Терлек азыгы өчен клевер, вика игәләр. Кузаклы культураларны гадәттә яз башында ук чәчәләр. Уңыш әйбәт була: бер бөртектән 100-150 шәр бөртек җыеп алына. Кузаклыларны, аксымы бик күп булганга, еш кына үсемлек ите диләр.

Кузаклы үсемлекләр **игенчелек** өчен бик әһәмиятле. Аларның тамырларында кечкенә бүлбеләр оеша, шул бүлбеләрдә **һавадагы** азотны үзләштерә торган махсус бактерияләр яши. Менә шуның өчен кузаклылардан соң **туфракта** азот күп була. Соңыннан шул ук җиргә чәчелә торган бодай, кукуруз һәм бүтән төрле үсемлекләр өчен азот бик файдалы.

| | |
|---|---|
| **аксым - белок** | **кузаклылар – бобовые** |
| **бодай - пшеница** | **ногыт борчагы – фасоль** |
| **бүлбе – клубень** | **ясмык – чечевица** |

**Бу кызык!**

**Андыз** – “девясил, аир” – чув. *антас*; мар. *андыз*; удм. андъс; бор. төрк. *андыз* - “андыз үләне” сүзеннән. Кыпчак һәм угыз төрки телләрендә *аңдыз* “аңду, посып каравыллап тору” (урыны). Андыз үләне биек һәм зур яфраклы була, аның артына кереп яшеренергә бик җайлы, килеп чыгышы шуның белән аңлатыла.

**Бәрәңге** – “картофель” – күп кенә тикшеренүчеләр бу сүзне рус теленнән кергән алынма сүз дип карага тырышалар, ләкин ул тулысынча төрки лексик чаралар тәэсирендә ясалган. Бор. болгар - *бүәрәңке*, чуваш т.– *пуранха, паранха* – “бәрәңге”, бурят т. *боорэнхы* – “йомры, шарсыман”, монг б*огўреңкәй* “йомры, йомры бер нәрсә”.

**5. Биремнәр.**

1. Текст ахырындагы сүзләрне тиешле урыннарга куеп, текстны укыгыз һәм тәрҗемә итегез.
2. Текстның эчтәлеген сөйләгез.

3. Алгы рәт сузыкларыннан торган сүзләрдән сорау җөмләләр, арткы рәт сузыклардан торганнарыннан хикәя җөмләләр төзегез.
4. Курсив белән бирелгән җөмләне “тәртипкә китерегез”.

Көнчыгыш халыкларында мондый мәкаль бар: “Җәнлекләр патшасы – юлбарыс, ................. патшасы – женьшень. Чынлыкта ............“җәнлекләр патшасы”на охшаса да, “үсемлекләр патшасы” бөтенләй күренекле түгел. Аның .................тар гына, җимеше – вак кына тәмсез җиләк. *Ә эре кеше тамыры һәм гәүдәсенә итләч охшаган, тыгыз менә була*. Бик кыйммәт бәяләнә торган шушы тамырны эзләп, женьшень җыючылар айлар буе ...................................... йөргәннәр. Тайгада һәлак булып калганнар, әмма шул .............. тамырны эзләү өчен яңадан-яңа кешеләр киткән.

Женьшень – .............. “тереклек тамыры” дигән мәгънәне аңлата. Бу үсемлекне юкка гына шулай атамаганнар һәм ул юкка гына шулай кыйммәт йөрмәгән: женьшеньнан бик каты авыруларны дәвалый торган ............. ясала. *Сирәк азая ләкин – очрый ул женьшень барган үсемлек елдан-ел торган.* Кешеләр женьшеньны үзебез үстерә алмабызмы дип уйлана башлыйлар. Бу җиңел түгел, әмма кешеләр аны ........... женьшень плантацияләрендә үстерергә өйрәнделәр. *Ерак андый бар Көнчыгышта һәм Азиядә Урта плантацияләр.*

**дару – лекарство** — **тылсымлы - волшебный**
**кытайча – по-китайски** — **тамыр – корень**
**махсус - специальный** — **үсемлек - растение**
**сабак – стебль** — **юлбарыс - тигр**

**6.Биремнәр.**
1. Күпнокталар урынына тиешле сузыкларны куеп, үсемлек атамаларын дәфтәрегезгә күчереп языгыз, сүзлекчә (51-55 битләр) ярдәмендә тәрҗемәләре белән танышыгыз.
2. Ирен гармониясенә буйсынган сүзләрнең асларына сызыгыз.
3. Арткы рәт сузыкларыннан гына торган сүзләр һәм сыйфатлар ярдәмендә сүзтезмәләр төзегез. *Үрнәк: татлы борыч, кара шомырт һ.б.*
4. Ике үсемлек турында диалог төзегез.

*Б...рыч, ш...мырт, н...гыт, т...рма, с...лы, т...рнабаш, ч...рмавык;*
*Б...тнек, х...рмә, г...лҗимеш, г...лчәчәк, с...тлегән, й...зем, к...нбагыш;*
*К...на, к...ч...ткан, т...рнак гөл, ч...клы үлән, к...залак, с...рганак;*
*С...ркәч, ...рбет агачы, м...ңьяфрак, к...ләнчел, б...зүлән, ....нҗ... чәчәк.*

**Бу кызык!**

**Кашкарый – “астра**” – к. диал. *кашгарый* “кашкарый, астра, кашгар гөле” (Кашгар – Синьцзяньдә бер зур өлкә).

## §4. Татар телендә иҗек төрләре

**Укыгыз һәм истә калдырыгыз!**
Иҗек – сөйләмнең (әйтелешнең) иң кечкенә берәмлеге.

Татар телендә сузык аваз, күп кенә башка телләрдәге кебек, иҗек ясаучы аваз булып тора. Татар сүзләрендә гадәттә тартык һәм сузык чиратлашып киләләр. Беренче һәм икенче иҗек төрләре бары тик сүзнең беренче өлешендә кулланылалар. Татар телендә иҗек бервакытта да ике тартыктан башланмый, әмма иҗек ике тартык белән тәмамланырга мөмкин. Бу ике тартыкның берсе, нигездә беренчесе, һәрвакыт сонор була (л, м, н, й, р). Сүз V, VI иҗек төрләре турында бара. Татар сүзләрендә әлеге иҗек төрләре бик сирәк очрый. Татар телендә иҗекнең түбәндәге төрләре бар:

**I** С – **у**-мыр-за-я, **а**-ба-га.
**II** СТ – **ут**-чә-чәк, **ар**-па
**III** ТС – **дү-лә-нә**, **та-ры**
**IV** ТСТ - **бал-тыр-ган, бор-чак**
**V** СТТ – **урт**, **ант**
**VI** ТСТТ - **корт**, **сырт**-лан

**7. Биремнәр**.

1. Шәүкәт Галиевнең “Кычыткан” шигырен сәнгатьле итеп укыгыз.
3. Шигырьдәге *Аягына ут элгән* дигән юлларны ничек аңлыйсыз?
2. Асларына сызылган сүзләрне иҗекләргә бүлегез, нинди уртаклыкларын күрәсез?

Әрекмән ни, әрем ни,
Әсма **шул** әле белми.
**Белгән** дә ул, оныткан,
Нинди була кычыткан?
Танымый шул, танымый.
Танымаса тагы ни,
**Бик** кирәк ди кычыткан!
Әсма урамга **чыккан**,
Койма буена **кергән**.
Сикергән дә үкергән,
**Ник** кергәнгә үкенгән –
Аягына ут элгән!
**Яндырган** да пешергән,
...Үзен искә төшергән,
Кара **син** кычытканны –
Яратмый оныткканны.

(Шәүкәт Галиев).

**8. Биремнәр.**

1. **w** авазы кергән сүзләрне бер баганага, **в** авазы кергәннәрен икенче баганага күчереп языгыз.
2. Түбәндәге бер үсемлек турында сөйләргә әзерләнегез.
3. Сүзлекчә ярдәмендә (51-55 битләр) үсемлек атамаларының русча тәрҗемәләре белән танышыгыз һәм аларны истә калдырыгыз.

*Агава, айравык, балавыз агачы, валериан, сазлавык уты, лаванда, чикләвек, чормавык, эвкалипт, ак калкавыч гөмбә, вика, кавын, вистерия, шыгырдавык гөмбә*.

**9. Биремнәр.**

1. Текстны татарчага тәрҗемә итегез, төп эчтәлеген дәфтәрегезгә язып куегыз.
2. Әлеге үсемлекнең дәвалау үзенчәлекләре турында төркемдәшләрегез белән сөйләшү уткәрегез.

Тмин обыкновенный (лат. – Carum carvi) в культуре известен со времён доисторических свайных построек неолита – уже тогда, в течение многих тысячелетий, наши предки часто применяли его в пищу. Латинизированное название тмина происходит, по всей видимости, от греческого «карон» – именно так называли тмин древние греки, разглядев за формой соцветия-зонтика голову (греческое слово «кара»). Кстати, арабское название тмина (карвиа) очень созвучно греческому. Возделывается тмин как двулетняя культура (имеются также однолетние сорта) почти во всех странах

умеренного пояса, в том числе в Украине (в Крыму встречается в диком или одичавшем виде), на Кавказе, в странах Средиземноморья и Средней Азии. Урожай (до десяти центнеров семян с одного гектара посевов) тмин даёт на второй год. Однажды средиземноморские биологи решили проверить, в какие сроки выгоднее разводить тмин, чтоб не растрачивать драгоценную влагу на полив, и выяснили, что тмин лучше сеять попозже, в конце осени, когда становится прохладнее. Это и не удивительно. Ведь тмин – выходец с севера

**латинизированное название – латинлаштырылган исеме, атамасы**
**одичавший вид – кыргыйлашкан төр**
**соцветие – чәчәк төркеме, укмаш чәчәк**
**однолетние сорта - берьеллык төрләре**
**тмин обыкновенный - ак әнис**

**10. Биремнәр.**

1. Текстны укыгыз,эчтәлеген сөйләргә әзерләнегез.
2. Курсив белән бирелгән җөмләләрне сорау җөмләләргә әйләндерегез.
3. Тексттан түбәндәге схемаларга туры килгән сүзләрне табып, дәфтәрләрегезгә күчереп языгыз(СТ-ТСТ, С-ТСТ, СТ-ТСТ, ТС-ТСТ). *Үрнәк: СТ+ТСТ – ан-нан.*
4. Имән турында үзегез белгән мәгълүматларны өстәп, диалог төзегез.
5. Үзегезгә ошаган бер агач турында монолог әзерләгез.

*Имән бик озак – 1000әр ел яши*. Баштагы 80 елда ул биеклеккә үсә, аннан соң калыная гына. *Аның биеклеге 50 шәр метрга җитә.*

Кәүсәсе ныгыгач һәм ябалдашы зурайгач, имән куәтләнә. Ә имән чикләвегеннән әле генә үсеп чыккан кечкенә имән күрше куакларның ярдәменә мохтаҗ була. Урман караучылары юкка гына: “Имән үзе тун эчендә, әмма яланбаш үсәргә ярата”, - димиләр. Бу болай дигән сүз: ул яктыга омтыла, өске өлешенә күләгә төшкәнне яратмый. *Әмма аның янында яшь имән, каен, чыршы әйбәт үсә.*

*Имән, куәтле булса да, көчле салкыннарга чыдамый, артык эссене дә яратмый*. Шул сәбәпле ул Санкт-Петербургтан һәм Вологдадан төньякта, Себердә һәм илебезнең көньягында үсми.

Имән бик борынгы заманнардан ук хуҗалыкта кулланылган. Имән агачы нык була. Ул суда череми, шуңа күрә күпер субайларын күбесенчә имәннән ясыйлар. *Имән агачын судно һәм вагоннар төзегәндә кулланалар, аннан йортлар салалар, кисмәк тактасы ясыйлар*. Имән – ул гаҗәеп шәп паркет, матур фанер, әйбәт утын.

**кәүсә - ствол**
**куак – куст, кустарник**
**омтыла – стремится**
**мохтаҗ – нуждающийся в чём-нибудь**
**куәтләнә – становится мощным, сильным**
**урман караучы - лесник, лесничий.**

**11.Биремнәр.**

1. Агулы үсемлекләр турындагы текстны татарчага тәрҗемә итегез.

2. Тагын нинди агулы үсемлекләрне беләсез? Киләсе дәрескә 1-2 агулы үсемлек турында татарча презентация ясап, сөйләргә әзерләнеп килегез.
3. Агулы үсемлекләргә кагылышлы кагыйдәләр уйлап табыгыз һәм аларны укып күрсәтегез.



**Волчник, или волчье лыко** в народе называют волчьей ягодой. Это кустарник или мелкие деревца с ярко-красными ягодами, похожими на облепиху. Сок этого ядовитого растения, попавший на кожу, может вызвать боль, красноту, отек, и даже пузыри и язвы (глубокие дефекты кожи, после их заживления остаются рубцы). При попадании ягод или сока в желудок, признаки отравления будут такими: жжение во рту и глотке, затруднение глотания, слюнотечение, боли в желудке.



**Вороний глаз.** Известно несколько видов этого растения. В нашей полосе особенно распространен вороний глаз четырехлистный. Его высота 15 - 30 см, четыре листа располагаются на верхушке стебля, цветок зеленовато-желтый, плод – черная шаровидная ягода. Ядовиты все части растения, но особую опасность представляют плоды - одиночные ягоды сизовато-черного цвета, которые ребенок может принять за чернику или голубику. Случаи смертельного отравления вороньим глазом не известны.



**Белена черная.** Это двулетнее травянистое растение с неприятным, дурманящим запахом из семейства пасленовых очень ядовито, особенно во время цветения. Все растение опушено мелкими, мягкими волосками. Плод растения – коробочка с буровато- черными семенами округлой формы. Дети часто принимают их за маковое семя, а мясистый стеблевой корень - за корни овощных растений.

**Бу кызык!**

**Балтырган – “борщевик”-** бор. *бал-тар* “җитлекмәгән тереклек, яшь үлән, бәбәк” алтай, тува т. *палдырган* “үсемлек төбе, бер төптән үскән сабаклар төркеме, балтырган” , казакъ т. *балдырган* “яшь үлән, курпы; буыны ныгымаган бала”, *балдыр* “су төбендә үсә торган йомшак үлән, яшь кеше”. Сүзнең тамыры - *балды – “үсү, тармаклану, курпылау”* борынгы телләрдән сакланган. Балдыз сүзенең тамыры да шуңа барып тоташа.

**Ногыт – “бобы”** – уйгур т. *нокут*, фарсы т. *нохуд, нохут* “борчак, ногыт” сүзеннән. Бор. рус. т. *нохоть* “борчак”; элегрәк ногыт борчагы белән күрәзәләү киң таралган булган, шуннан чув.т. *нухат* “күрәзәләү”, коми т., мари т. *ногыт* “күрәзәләү өчен вак шакмаклар”.

**12. Биремнәр.**

1. Текстны укыгыз һәм асларына сызылган сүзләрне иҗекләргә бүлеп, дәфтәрләрегезгә күчереп языгыз, иҗек төрләрен билгеләгез. Әлеге сүзләр турында 3-4 җөмләдән торган мәгълүмат языгыз.
2. Текст ахырындагы таблицаны тутырыгыз.
3. Үзегез белгән күренекле биолог турында диалог төзегез.
4. Текстны кисәкләргә бүлегез һәм аларга исемнәр бирегез.
5. Чарлз Дарвин турында монолог сөйләргә әзерләнегез.

Чарлз Дарвин Англиянең Шрусбери шәһәрендә туа. Ул кечкенәдән үк кырларда, урманнарда йөрергә ярата, тирә-яктагы табигатьне күзәтә. Чарлз үз күзәтүләрен китапта укыганнары белән чагыштыра. Малай, бик мавыгып, кабырчыклар, минераллар, кош йомыркалары җыя. Коллекция өчен ул оядан бер генә йомырка алып, башкаларын урыннарында калдыра.

1831 елның язында Чарлз Дарвин Кембридж университетының дин гыйлеме факультетын тәмамлый, ләкин священник булудан баш тарта. Аның бөҗәкләрне һәм үсемлекләрне өйрәнәсе килә. Профессор Генслонның тәкъдиме буенча, аны Җир шары тирәли сәяхәт итәргә китә торган җилкәнле “Бигл” судносына алалар. Дарвинга шушы сәяхәт вакытында геологиядән, зоология һәм ботаникадан коллекцияләр җыю йөкләнә. Биш елга сузылган бу сәяхәтне ул “Натуралистның “Бигл” кораблендә дөнья тирәли сәяхәте” дигән китабында тасвирлый.

Дарвин дөньяны алла яратмаган дигән ныклы фикергә килә. Җир йөзендә төрле үсемлек һәм хайваннарның ничек барлыкка килүен аңлатуны табигатьнең үзеннән эзләргә кирәк, ди ул.

Сәяхәттән кайткач, Чарлз Дарвин, бик тырышып, үз фикерләрен раслаучы дәлилләр эзли башлый. Ул йорт хайваннарын өйрәнә, йөзләгән китапны яңадан укып чыга, алардан бик күп өземтәләр күчереп ала. Бу эш бик озак елларга сузыла һәм 1859 елда ул үзенең теориясен аңлаткан китап чыгара.

Кешенең хуҗалыгында кыргый табигатьтә булмаган бик күп үсемлек һәм хайваннар бар. Ләкин, һичшиксез, кайчандыр аларның кыргый бабалары булган. Шуның өстенә, бу кеше үсемлек һәм хайваннарның әллә никадәр сортын үзе китереп чыгарган. Кәбестә, алма, грушаның әллә ничә төрле сортын, эт, сарык, сыер, атның төрле токымнарын галимнәр ясалма сайланыш юлы белән китереп чыгарганнар.

Дарвин, “Бәлки, кыргый табигатьтә дә төрләр шундый сайланыш юлы белән барлыкка киләдер?” – дигән. Хайван һәм үсемлекләр, гадәттә, бик күп нәсел бирә бит. Һәр агачтан ел саен әллә никадәр орлык тарала. Ләкин аларның бик азы гына, тиешле шартларга эләгеп, шытып чыга һәм зур агач булып үсә. Мәсәлән, кайбер балыклар миллионлаган уылдык чәчә, ләкин аларның күбесе һәлак була. Уылдыктан чыккан вак балыкларның да бик сирәге генә үсеп җитә: аларны я ерткычлар ашый, я алар җайсыз шартларга эләгеп үлә. Иң җайлашучаннары, иң көчлеләре иң җитезләре генә исән кала. Табигатьтә билгеле бер шартларга яхшырак җайлашкан хайван һәм үсемлекләрнең сайланышы шулай бара. Дарвин бу процессны табигый сайланыш дип атаган.

| Җөмләләрне укыгыз һәм текстның эчтәлегенә туры килү-килмәвен билгеләгез | туры килә | туры килми |
|---|---|---|
| 1.1831 елның язында Чарлз Дарвин Кембридж университетының табигать белеме факультетын тәмамлый | | |
| 2.Дарвинга сәяхәт вакытында геологиядән, зоология һәм ботаникадан коллекцияләр җыю йөкләнә. | | |
| 3.1879 елда ул үзенең теориясен аңлаткан китап чыгара. | | |
| 4.Табигатьтә билгеле бер шартларга яхшырак җайлашкан хайван һәм үсемлекләр нең сайланышы Дарвин табигый сайланыш дип атаган. | | |
| 5.Ул йорт хайваннарын өйрәнә, йөзләгән китапларны яңадан укып чыга, алардан бик күп өземтәләр күчереп ала. | | |
| 6.Биш елга сузылган бу сәяхәтне Дарвин “Дөнья тирәли сәяхәте” дигән китабында тасвирлый. | | |

**13. Биремнәр.**

1. Диалогны сәнгатьле итеп укыгыз, эчтәлеге буенча фикер алышыгыз.
2. Әлеге диалог үрнәгендә төркемдәшегез белән әңгәмә корыгыз.

- Исәнме, Фәридә!
- Исәнме, Ләйсән!
- Ялларың ничек үтте? Рәхмәт, яхшы гына үтте, тик ял итеп кенә булмады.
- Ник алай дисең?
- Бүген ботаникадан реферат тапшыруның соңгы көне иде бит. Ял көннәрендә реферат язу белән мәшгуль булдым.
- Алай икән... Мин узган атнада тапшырган идем инде.
- Шулаймыни?! Ә рефератыңның темасы ничек иде соң?
- О-о, минем тема бик кызыклы иде, бөҗәк ашаучы үсемлекләр турында.
-Чыннан да, кызыклы тема. Андый үсемлекләр турында ишеткәнем бар иде, тик берсенең дә исемен хәтерләмим. Алар тропик урманнарда гына очрый, әйеме?
- Нигездә шулай, тик безнең якларда да андый үләннең бер вәкиле бар?
- Нинди үлән инде ул?
- Чыклы үлән.
- Чыклы үлән?!
- Әйе, русчасы “росянка” була. Ул сазлыктагы мүк түмгәкләре өстендә үсә икән. Аның биеклеге нибары 10-15 сантиметр гына. Яфраклары вак бөҗәкләрне, әйтик, черкиләрне, тоту өчен төкчәләр белән капланган. Бу үләнне сөялләрне бетерү, салкын тигәндә ютәлне басу өчен файдаланалар икән.
- Рәхмәт, бик кызык мәгълүмат булды бу. Я, ярый, мин китим инде, рефератны тапшырырга кирәк. Дәресләрдән соң, гадәттәгечә, һәйкәл янында очрашырбыз.
- Яхшы, очрашканчыга кадәр!
- Сау бул!

**14. Биремнәр.**

1. Китап ахырындагы сүзлекчә ярдәмендә түбәндәге үсемлек атамаларының русча тәрҗемәләре белән танышыгыз һәм аларны истә калдырыгыз.
2. Калын **г** авазы кергән сүзләрне кертеп җөмләләр төзегез.
3. Нечкә г авазы кергән сүзләр(үсемлек атамалары) турында диалог әзерләгез.

*Абага, өрәңге, кузгалак, балтырган, бөергән, груша, гөнҗә, карлыган, гөлбадран, кыңгырау гөл, ногыт, сөтлегән, сырганак, гөрежҗә, карагай.*

## §5.Татар телендә сүз басымы

**Укыгыз һәм истә калдырыгыз!**

Татар телендә басым гадәттә соңгы иҗектәге сузык авазга төшә. Кушымча ялганган саен, басым шул кушымчадагы сузык авазга күчеп бара: *җимеш-ләр-ем-не.* Ләкин телдә барлык кушымчалар да басымлы түгел. Басымсыз кушымчалар үзләренә басымны кабул итмиләр. Мәсәлән, фигыльләрдәге юклык кушымчалары ***–ма/-мә*** шундыйлардан. Рәвеш ясагыч ***–ча/-чә, дай/-дәй, -тай/-тәй*** кушымчалары да шундый үзенчәлеккә ия*: кеше-чә, кояш-тай*. Фигыльләрнең зат-сан кушымчалары да басымсыз булалар: *барыр**мын**, киткән**сез**.*

Кайбер аерым очракларда басым соңгы иҗеккә төшмәскә мөмкин. Бу түбәндәге:

- алынма сүзләрдә басымның урыны төрле булырга мөмкин: *телевизор, сумка.*
- сорау алмашлыкларында басым һәрвакыт беренче иҗеккә төшә: *ничә, нинди, кайчан* һ.б.
- кушма сүзләрдә басым беренче компонентның беренче яки икенче иҗегенә төшә: *ташбака, карабүрек* һ.б.
- кайбер сүз арты кисәкчәләре басымсыз булалар: (сорау) *мы/ ме*, (билгесезлек) *дыр/ дер, тыр/ тер*: синме, киләдер һ.б.
- күп кенә теркәгечләрдә басым беренче иҗеккә төшә: *ләкин, әмма, чөнки* һ.б.
- боерык фигыльнең икенче зат берлек һәм күплек сан формаларында басым беренче иҗеккә төшә: *укы, укыгыз* һ.б.
- көчәйткеч кисәкчәләре(сүз алды) басымлы булалар: *сап-сары, зәп-зәңгәр* һ.б.
- юклык алмашлыклары: *һичкайчан, берничек* һ.б.
- билгесезлек алмашлыклары: *кайчандыр, ничектер* һ.б.

**15. Биремнәр.**

1.Текстны укыгыз, эчтәлеген сөйләргә әзерләнегез.
2.Басымның соңгы иҗеккә төшмәгән очракларына мисаллар табыгыз, фикерегезне дәлилләгез.
3.Текст буенча 7-8 сораудан торган кроссворд төзегез.
4. Тексттагы яңа сүзләрне тәрҗемә итегез һәм сүзлек дәфтәрләрегезгә язып алыгыз.
5. Калын хәрефләр белән бирелгән суүсемнәр турында монолог әзерләп килегез.

Җир йөзендә суүсемнәр бик күп төрле. Алар арасында биеклекләре 40 ар м га җиткән гигантлар да бар – алар океаннарда үсә. Нибары бер генә күзәнәктән торган бик кечкенә суүсемнәр дә бар. Гадәттә алар колонияләргә туплана. Менә шул гаять күп колонияләр, өстә генә йөзеп¸суны төрле төсләргә кертәләр дә инде. Суүсемнәр зәңгәрсу-яшел, яшел, көрән һәм кызыл төсләрдә була. Зәңгәрсу-яшел суүсемнәр Казахстан һәм Урта Азия чүлләрендә , хәтта туфрак өстендә дә яшиләр. Язын һәм көзен, бу урыннарда яңгырлар күп яуган чакта, зәңгәрсу-яшел суүсемнәр бик күпләп үсә. Коры вакытта алар кибә һәм туфракны каплап ала. Җил бу катламны төрле якка

тарата. Яңгырлар башлану белән үк, бу зәңгәрсу-яшел суүсемнәр яңадан җанлана. Яшел суүсемнәр дә туфрак өстендә яши ала, тик шулай да алар күбесенчә суда очрый. Алар арасында бер күзәнәкле бик кечкенә суүсемнәр дә бар – алар су өстенә якын гына бик иркен йөзеп йөри, бик эре суүсемнәр дә бар – алары су төбенә ябышып үсә. Көрән суүсемнәр бик эре була. Диңгез һәм океаннарда алар су асты чытырманлыклары- чын джунглилар хасил итә. Саргасс диңгезендә **саргасс** дигән суүсемнәр үсә. Диңгезне дә шул исем белән атаганнар. Яр буйларында саргасслар диңгез төбенә берегәләр, ә ачык диңгездә йөзеп йөриләр. Алар шулкадәр күп була, хәтта судноларга йөзәргә комачаулыйлар.

Кызыл суүсемнәр дә диңгез һәм океаннарда үсә, тик алар йөзеп йөрми, бәлки кыяларга, бака кашыгы яки бүтән суүсемнәргә берегеп яши.

Су өстенә якын гына йөзеп йөри торган вак суүсемнәр ишкәк аяклы **кыслачыклар** һәм башка кечерәк диңгез хайваннары өчен азык була. Ә бөтен бу диңгез хайваннарын, үз чиратында, балыкларның күбесе бик яратып ашый. Суүсемнәр диңгез хайваннарына азык булулары өстенә, суны кислородка баеталар, череткеч бактерияләрдән чистарталар. Аларның күбесен кеше азык итеп куллана. Алар арасында безнең төньяк диңгезләрдә үсә торган **ламинария** дә бар.

Суүсемнәр – йорт терлекләре өчен яхшы азык. Алар, череп, сулык төпләрендә ләмнең калын-калын катламнарын – сапропель хасил итәләр. Бу ләм йорт терлекләренә ашатырга яраклы һәм бик әйбәт ашлама да. Суүсемнәр дәвалау максатларында да кулланыла. Моннан тыш, аларны күп төрле химик продуктлар алу өчен дә файдаланалар.

**16. Биремнәр.**

1.Басымнарны дөрес куеп, текстны укыгыз.

2.Калын хәрефле сүзләрне дәфтәрләрегезгә күчереп алыгыз һәм басымнарын куеп чыгыгыз.

3.Гөмбә җыярга баруыгыз турында төркемдәшегез белән әңгәмә корыгыз.

4.Текстның төп эчтәлеген 4-5 җөмлә белән әйтеп бирегез.

5.Китап ахырындагы сүзлекчәдән гөмбәләрнең татарча-русча атамаларын өйрәнеп килегез.

Гөмбә җыйганда, җирдән **күбесенчә** гөмбә белән аның гөмбәлеге дә – нечкә, озын җепселләре дә чыга. Бу нечкә җепселләр үсемлекнең үзе - **ягъни** гөмбә. Ә без гадәттә гөмбә дип йөрткәнебез – **үсемлекнең** “җимеше”.

Менә агач төбендә гөмбә үскән. Аның дөньяга килгәненә бер генә көн. Ә агачына байтак яшь. **Гөмбәлек** тә аның белән бер яшьтә, алар бергә үскәннәр. Гөмбәлекләр күп вакыт агач тамырларының очына чорналалар. Бу аларның икесе өчен дә уңай. Агач гөмбәгә әзер азык – тамырлар бүлеп чыгарган шикәр бирә. Ә гөмбә агачны туфракның **матдәләр** таркалу продуктлары белән тәэмин итә.

Гөмбәләр дөньясы бик бай. Әйтик, галимнәр җир шарында гөмбәләрнең 100 мең чамасы төрен ачыклаганнар. Билгеле, алар арасында микроскоптан гына күренә торган **гөмбәчекләр** төр составы ягыннан

күпчелекне тәшкил итә, гади күз белән күреп була торганнарының һәм **шактый** зурларының 7 меңләп төре исәпләнә. Шуларның 3 мең төре элекке СССР территориясенә туры килә. Идел буе җирләрендә 200 дән күбрәк ашарга яраклы гөмбә төре исәпләнә.

**17. Биремнәр.**

1. Текстны тәрҗемә итегез. Эчтәлеген сөйләгез. Сүз кайсы гөмбә турында бара?
2. Рәсем буенча 5-6 сорау әзерләгез.



По своему строению ................ относится к группе трубчатых, а по пищевой ценности входит во вторую группу. Шляпка мясистая, сначала шаровидная, затем подушкообразная, окраска ее желтовато-красная, буро-красная, оранжево-красная. Нижняя поверхность шляпки сначала белая, затем сереет. Ножка прямая, высокая, у основания утолщенная, белая с темно-коричневыми чешуйками. Мякоть плотная белая, при изломе сначала синеет, затем становится черно-фиолетовой. ................... является одним из любимых грибов у грибников. Здесь роль играет и большое количество этих грибов, и нежный насыщенный вкус.

**18. Биремнәр.**

1.Түбәндәге сүзләрнең басымнарын куеп, дәфтәрләрегезгә күчереп языгыз, ярымдифтонглы сүзләрнең асларына сызыгыз.

2. Гөмбә исемнәренең тәрҗемәләре белән танышыгыз һәм икесе турында диалог төзеп сөйләгез.

3. Бер гөмбә турында татарча презентация әзерләгез.

*Майлы гөмбә, гади яз гөмбәсе, йолдызсыман гөмбә, каен гөмбәсе, усак гөмбәсе, куык гөмбә, әтәч гөмбәсе, шыгырдавык гөмбә, җирән гөмбә.*

**18. Биремнәр.**

1.Текстны татарчага тәрҗемә итегез.

2.Түбәндәге сорауларга җавап бирергә әзерләнегез.

*Җирән гөмбәнең нинди төрләре бар? Җирән гөмбәләр бер-берсеннән ничек аерылалар? Җирән гөмбә кайда һәм ничек үсә? Җирән гөмбәнең нинди файдалы үзенчәлекләре бар? Җирән гөмбәдә нинди витаминнар һәм микроэлементлар бар?*

Рыжик – гриб с концентрическими кругами на шляпке, ямками на плодовой ножке и характерным млечным соком оранжевого цвета из семейства Сыроежковые. Рыжик растет поодиночке или группами среди травы и опавшей хвои в ельниках, сосновых борах или под отдельно расположенными соснами в смешанных лесах европейской части России, Сибири, Урала и Дальнего Востока. Наиболее часто встречаются чрезвычайно похожие друг на друга четыре вида рыжиков: настоящие, красные, еловые и сосновые. Внешне они немного различаются в зависимости от условий произрастания. Например, еловый рыжик отличается зеленоватой окраской шляпки, меньшими размерами и более сильным специфическим запахом по сравнению с сосновым. Но грибники обычно

предпочитают яркие и красивые сосновые и красные рыжики, несмотря на то, что они немного уступают по вкусовым качествам двум другим видам.

В рыжике содержатся витамины В1 и А, способные улучшить зрение, состояние кожи и волос, а также микроэлементы (кальций, калий и фосфор) и противоревматическое вещество, обладающее противовоспалительным эффектом.

**рыжик красный – кызгылт җирән гөмбә** **сыроежковые – ал гөмбәләләр**
**рыжик сосновый – нарат җирән гөмбәсе** **рыжик еловый – чыршы җирән гөмбәсе**

**19.Биремнәрне үтәгез.**

1. Шәүкәт Галиевнең "Син таныйсыңмы?" шигырен сәнгатьле итеп укыгыз. Шигырьнең соңгы юлларын ничек аңлыйсыз? Шул турыда төркемдәшләрегез белән әңгәмә корыгыз.
2. Шигырьне яттан сөйләргә әзерләнегез. Татар авазларының дөрес әйтелешенә игътибар итегез.

Белмәгәнгә ни –
Барсы бер лә:
Гөмбәме, гөмбә –
Кайсысы яхшы,
Кайсысы яман,
Аермый бер дә.

Ә соң син үзең
Гөмбә җыюның
Җаен беләмсең –
Таный беләмсең,
Нарат гөмбәсен,
Каен гөмбәсен?

Бу – әтәч гөмбә
Адашкан мәллә
Килеп урманга?
Кәҗә гөмбәсе
Бүредән ничек
Курыкмый анда?

Бусы ак гөмбә,
Анысы ал гөмбә,
Син таныйсыңмы?
Чынын ялганнан
Аерасыңмы,
Бутамыйсыңмы?

Мәкерле ялган
Чын кыяфәтен
Үзенә алган -
Кешеләр чынны
Яратканны ул
Сизенеп калган!

Ә менә монсы
Нинди гадәти
Төскә кермәсен,
Аера бел син, -
Елан гөмбәсе -
Чага күрмәсен!

Гөмбәне генә
Түгел, дөньяны
Син таныйсыңмы?
Чынны ялганнан
Аерасыңмы,
Бутамыйсыңмы?

(Шәүкәт Галиев).

**Бу кызык!**

**Гөмбә –** "гриб" – Көнчыгыш Европада киң таралган символик яңгырашлы тамыр сүз: рус. *губа, гунба*, "гөмбә, буа болыты", коми. *гоб* "гөмбә", венг. *gomb* "шар", талыш. *гобалай* "гөмбә", монг. *бумба* "шарсыман нәрсә, шар, бомба", санкрит. *bumbul* "шарсыман нәрсә".

**20.Биремнәр.**

1.Рәсемдәге гөмбәләрне таныйсызмы?  Алар турында  нәрсәләр беләсез, шул хакта монолог төзегез.
2. Рәсем буенча сораулар бирегез.
3. Ашарга яраклы һәм агулы гөмбәләр турында кабатлап сорау алымын кулланып, диалог төзегез.




К е т. Г р и б ы. 1. Белый. 2. Подосиновик. 3. Желчный. 4. Сатанинский. 5. Моховик зеленый. 6. Подберезовик. 7. Масленок еловый. 8. Масленок лиственичный. 9. Рыжик. 10. Волнушка. 11. Свинушка. 12. Сыроежка зеленая. 13. Сыроежка лиловатая. 14. Сыроежка охристая. 15. Сыроежка жгучеедкая. 16. Валуй.

**21.Биремнәр.**

1.Текстны татарчага тәрҗемә итегез.
2.Татар теленә тәрҗемә ителгән өч җөмләне әйтеп яздырыгыз.
3. Ялгызлык исемнәрне сүзлек дәфтәрләрегезгә язып алыгыз һәм тәрҗемә итегез.
4.Текст ахырындагы сүзләрнең тәрҗемәләрен истә калдырыгыз.

**Жасмин** - вечнозеленый кустарник, всего существует около 200 его видов. У всех имеются вьющиеся стебли, которые могут достигать до 3 или даже 10 метров в длину, цветки, собранные в звездообразные соцветия. Листья могут быть простыми, тройчатыми, цветки - белыми, желтыми или красными, все это в зависимости от вида, но все они трубчатые, а внутри трубки находятся на коротких нитях 2 тычинки.

Традиционно родиной жасминов считаются Аравия и Восточная Индия. Жасмин лекарственный в основном произрастает в Малой Азии и Китае, а место обитания жасмина самбак - остров Цейлон. Кроме того, встречается жасмин также в тропиках и субтропиках Америки и Африки. Жасмин Биса произрастает на территории рек и гор Западного Китая, жасмин

желтый - на Кавказе и в средней Азии. В народной медицине жасмину нашли очень широкое применение - в лечебных целях используются цветки, листья, корни и побеги, кроме того, используются и семена, то есть можно сказать, что все части растения.

**вечнозеленый – мәңге яшел** **жасмин – ясмин**
**вьющиеся стебли – уралма, үрмә сабаклар** **побег - бәбәк**
**звездообразные – йолдызсыманнар** **тычинка – серкә**
**трубчатые- көпшәксыманнар** **тройчатый - өчбуынлы**
**соцветие – чәчәк төркеме, укмаш чәчәк** **обитание – яшәү урыны**

**22. Биремнәр.**

1. Текстны татарчага тәрҗемә итегез һәм эчтәлеген сөйләргә әзерләнегез.
2. Әлеге үсемлек турында тагын нәрсәләр беләсез, төркемдәшләрегез белән шул хакта әңгәмә корыгыз.
3. Текстның эчтәлеге буенча татар телендә 7-8 сорау төзегез һәм аларның җавапларын языгыз.

**Пижма обыкновенная** — многолетнее, довольно грубое, прямостоящее растение, до 1м высотой, образует несколько стеблей. Цветет растение с июня по сентябрь. Заготавливают молодые цветки его в июне-июле, а зрелые плоды осенью. Все растение имеет характерный камфорный запах, так как содержит эфирное камфорное масло.

**Географическое распространение**. По всей территории России, кроме Крайнего Севера и пустынных районов. Пижма обыкновенная растет на опушках, в луговых степях, березовых лесах, на суходольных лугах. На Украине — повсеместно, кроме районов крайнего юга.

В цветках и листьях пижмы содержится эфирное масло, количество которого зависит от времени сбора и от места произрастания. Максимальное содержание эфирного масла наблюдается в период цветения. Эфирное масло из цветков и листьев — жидкость желтого или зеленовато-желтого цвета.

Пижма как лекарственное средство была известна еще в средние века. Растение широко применяется в народной медицине. Водный настой цветочных корзинок возбуждает аппетит, усиливает секрецию желез желудочно-кишечного тракта и тонизирует его мускулатуру, улучшает пищеварение, увеличивает отделение желчи и пота, замедляет ритм сердца и повышает кровяное давление. Настой обладает жаропонижающим, противовоспалительным, обезболивающим действием.

**Бу кызык!**

**Нарат “сосна”** - монгол теленнән кергән булса кирәк; татар, чуваш башкорт, кумык телләрендә *нарат*, якут телендә *нурат*, “нарат, чыршы”. Күпчелек төрки телләрдә билгеле түгел, аның каравы монгол телләрендә киң таралган: бурят телендә *нархум, нарассуун, нарахунь*, монг. т. *нарас-сун, нара-т-сун* “нарат, чыршы”. Монгол телендә наран “кояш” сүзен аңлата.

**Чыршы** –«ель» - башк., *шыршы*, чув., мар. *чараш*, каракалпак *шыршы*, казакъ, кумык *шырыш* “сумала, җилем” (чыршы агачы, “җилем агачы, сумала агач”) сүзеннән. Соңгысы фарсы теленнән кергән дип санала.



**23. Биремнәр.**

1.Аның фәнни атамасы - «плантаго» латин теленнән тәрҗемәдә “табан асты” дигәнне аңлата. Бу үсемлекнең Ватаны – Аурропа илләре, индеецлар аңа “ак кеше эзе” дигән исем биргәннәр. Сүз нинди үсемлек турында бара?

2. Китаптан әлеге үсемлек турындагы текстны эзләп табыгыз һәм аны тәрҗемә итегез.

3. Рәсем буенча “әйе” яки “юк” дип җавап бирә торган сораулар әзерләгез. *Үрнәк: Бу ашый торган үсемлекме? Аның чәчәкләре озынчамы? һ.б.ш.*

**24. Биремнәр.**

1. Түбәндәге сүзләрнең русча вариантларын тексттан табыгыз һәм киләсе дәрескә алар белән сүзлек диктанты язарга әзерләнегез. *Биологик актив матдәләр вертикаль тамыр-сабак, дугасыман сеңерчә, тамыр таралгысы, чуклы тамыр, кыска бәбәк, күпьеллык үләнчел үсемлек, ялкынсынуга каршы тәэсир, яраларны төзәтү үзлеге, йомыркасыман конус рәвешендәге күп орлыклы тартмачык.*

2. Текстның эчтәлеге буенча татар телендә биш сорау әзерләгез һәм төркемдәшләрегездән төгәл җавап алырга тырышыгыз.

**Подорожник** - многолетнее травянистое растение семейства подорожниковых высотой до 25 см. Корень подорожника мочковатый, корневище вертикальное, побеги укороченные. Листья с дугообразными жилками, собраны в корневую розетку. Цветет с весны до осени. Цветки подорожника мелкие, серовато-розовые, образуют соцветие-колос. Плод — яйцевидно-коническая многосемянная коробочка. Созревает подорожник в июне. Биологически активными веществами листьев подорожника являются пектин, иридоиды, флавоноиды и сапонины. Пектин обладает ранозаживляющими свойствами. Иридоидный гликозид аукубин и продукты его распада оказывают выраженное противовоспалительное действие. Сапонины, пектиновые вещества, флавоноиды и оксикоричные кислоты подорожника способствуют уменьшению содержания холестерина в плазме крови. Препараты подорожника применяются при острых желудочно-кишечных заболеваниях (гастрите, энтерите и энтероколите), остром и хроническом колите, бронхите, атеросклерозе. Под влиянием сока подорожника быстрее очищается раневая поверхность от гнойных выделений, прекращается воспалительный процесс и ускоряется грануляция.

**Бу кызык!**

**Канәфер** –“гвоздика” – барлык төрки һәм башка телләрдә таралып, төрле яңгырашлар алган сүз: бор. төрки. *карамбул*, үзбәк теле *калампур*, фарсы т. *кәрәнфел,* бор. рус. *кануфер, калафур*, чуваш т. *калэмпер*. Асылда, гарәп теленнән.

**Гөл** - “цветок, цветы» - фарсы т. *гүл* “гөл, чәчәк” сүзеннән, шул ук тамырдан шулай ук фарсы теленнән *гөләндәм* “гөл гәүдәле”, *гөләп* “су гөле”, “ак чәчәк”, *гөлбадран* “ай гөл” һ.б. сүзләр алынган.

**Зәйтүн** – “олива” – гар. *зәйтүн-ун* “зәйтүн, майлы агач”, *зата* “майлау” тамырына нисбәт ителә, ләкин төптә Кытай порты Цзяодунь сүзеннән (зәйтүн элек шуннан китерелгән) булырга мөмкин.

# Контроль эшләр

### Татар теленең аваз төзелеше” темасы буенча тест (татар төркеме)

1.Кайсы пропорция дөрес түгел а)зәйтүн =сарут; ә) кыяр=пестә; б) борыч=киндер .
*2. **Төнбоек*** сүзендә а) 2 сузык 3 тартык; ә) 3 сузык, 5 тартык ; б)2 сузык, 4 тартык .
3. ***Чалмабаш*** сүзе кайсы вариантка туры килә а)ТСС+ТС+ТСТ; ә) ТСТ+ТСТ+ТСТ;б) ТСТ+ТС+ ТСТ.
4. Кайсы вариантта сүзләр алгы рәт сузыкларыннан гына торалар?
а) алабута, борыч, шомырт; ә) шәфталу, үтчәчәк, кузгалак; б) арпа, тары, киндер.
5. Кайсы сүзнең тәрҗемәсе дөрес түгел а) камчау - скабиоза; ә) пестә- каштан; б) сәрдә- сныть.
6. Кайсы вариантта сүзләр сонорлардан гына тора? а)дүләнә, ногыт; ә) әрем, яран; б) ясмык, бодай.
7. Ялган дифтонглы сүзләр кайсы вариантта?а)чорнавыч, нәүрүзгөл; ә) рәваҗ, хөрмә; б)кәстәнә, өянке.
8. Кайсы вариантта сүзләр яңгырау тартыклардан гына тора? а) ясмин, бәрәңге; ә) гөлбадран, сөмбел; б) тузганак, төнбоек.
9. Кайсы вариантта ирен гармониясе юк? а)ногыт, йөзем; ә) сөтлегән,гөлҗимеш; б) борыч, дөге.
10. Сингармонизм законына бирелгән дөрес аңлатманы билгеләгез: а)тартыклар ярашуын белдерә; ә) тартыклар һәм сузыклар ярашуын белдерә; б)сузыклар ярашуын белдерә.
11. Сингармонизмга буйсынган сүзләр кайсы вариантта? а) каен, сырганак; ә) алкагөл, әфлисун; б) казаяк, күкчәчәк.
12.Басымсыз кушымчалар кайсы вариантта а) килеш кушымчалары ә) тартым кушымчалары б) зат-сан кушымчалары.
13.W авазын белдергән хәрефләр ничәү? а) берәү; ә) икәү; б) өчәү.
14.Татар теленә тугандаш саналмаган тел кайсы вариантта а) гарәп; ә) чуваш; б)алтай.
15.Татар телендә ябык иҗек төрләре ничә? а)ике; ә) өч; б)дүрт.

### Тест по фонетике татарского языка (для русскоязычных студентов)

1. Какая пропорция неправильная а)үлән-суган; б) җитен-ногыт; в)хөрмә-торма
2. В слове ясмин а) 2 гласных, 3 согласных; б) 4 гласных, 2 согласных ; в)2 гласных, 4 согласных.
3. К какому варианту подходит слова меңьяфрак а)ТСС+ТС+ТСТ; б) ТСТ+ТСТ+ТСТ; в) ТС+С+ТС+ТСТ.
4. В каком варианте все слова состоят из гласных заднего ряда?
   а) арпа, тары, киндер; б) мәк, нәркис, дәлия; в)каен, усак, нарат.
5. Найдите неправильный перевод а) казаяк-лютик б) гөлҗимеш - шиповник; в) солы -пшено
6. В каком варианте все слова состоят из звонких согласных? а)шомырт,имән;
   б) яран, әрем; в)миләш, тузганак.
7. В каком варианте все слова с ложными дифтонгами? а)миләүшә, рәйхан;
   б) ясмин, шалкан; в) өянке, сарут.
8. В каком варианте все слова состоят из глухих согласных? а) дүләнә, дөге;
   б) күкчәчәк, пестә; в)борыч, кабак.
9. В каком варианте не выражается губная гармония? а) бодай; б) ногыт; в) сөмбел.
10. В татарском языке всего а) 8; б) 9; в) 7 гласных.
11. В татарском языке всего а) 27; б) 28; в) 24 согласных звуков.
12. В каком варианте все слова состоят из гласных переднего ряда? а)кузгалак, наратбаш;
   б) түндербаш, сәрдә; в) җитен, миләш.
13. В каком году татары перешли на кириллицу? а)1927; б)1938; в)1939.
14. В каком варианте все слова не подчиняются закону сингармонизма? а)аксыргак, тукранбаш; б) гөлбадран, рәйхан; в)тузганак, боабаб.

**Рус төркеме өчен тест**

**Үсемлек атамаларының русча тәрҗемәләрен билгеләгез**.

Дәлия – а)георгин; ә) магнолия; б) маргаритка.
Сырганак- а)лопух; ә) облепиха; б)черемица.
Дүңкәл- а)боярышник; ә) ирга; б)жимолость.
Усак- а)осина; ә) сосна; б)ясень.
Тукранбаш а)клевер; ә) вика; б) чечевица.
Гөреҗдә - а)гладыш; ә)груздь; б) рыжик.
Сөмбел – а)молочай; ә)гиацинт; б) нарцисс.
Билчән а)осот; ә) липучка; б) хвощ.
Куык гөмбә а)дождевик; ә) булавница; б) чага
Әспе а) скабиоза; ә) спаржа; б) полынь.
Әтәч гөмбәсе а)серушка; ә) лисичка; б) чернушка.
Җитен - а)конопля; ә) донник; б)лен.
Гөлбадран - а)пижма; ә) подорожник; б) девясил.
Торма а)репа ә)свекла;б) редька.
Солы - а) овёс ә) пшено; б) просо.

**Татар төркеме өчен тест**

**Үсемлек атамаларының татарча тәрҗемәләрен билгеләгез**.

Боярышник – а)дүңкәл; ә) дүләнә; б) күкчәчәк.
Имбирь- а)бәбрия; ә) сәрдә; б)зәнҗәбил.
Голубика- а)бөрлегән; ә) күк җиләк; б)мүк җиләге.
Каштан- а)өрәңге; ә) карагай; б)кәстәнә.
Ревень а)камчау; ә) рәваҗ; б) багульник.
Рыжик- а) җирән гөмбә; ә) әтәч гөмбәсе; б) ал гөмбә.
Маргаритка – а)алтын чәчәк ; ә) дәлия; б) чалмабаш.
Василёк а)гөлчәчәк; ә) күкчәчәк; б) тукранбаш.
Акация а) сәрви агачы; ә) чормавык; б) артыш.
Паслён а) эт тигәнәге; ә) бүре җиләге; б) эт җиләге.
Ячмень а)ясмык; ә) арпа; б) киндер.
Редиска - а)шалкан; ә) төче торма; б) ташкабак.
Терн - а)күк җиләк; ә) мүк җиләге; б) күгән.
Ясень а)корычагач; ә)карагай; б) тирәк.
Персик - а) дәфнә; ә)кавын; б) шәфталу.

***Реферат темалары*** (татар төркеме өчен)

1. Чарльз Дарвин һәм аның теориясе
2. Күзәнәкләр төзелеше
3. Үсемлекләр систематикасы
4. Таксономик берәмлекләр
5. Россиянең “Кызыл китабы”
6. Татарстан табигате
7. “Грипнис” (“Яшел дөнья”) халыкара экологик оешмасы
8. “Идел-Чулман” тыюлыгы
9. “Түбән Кама” милли паркы
10. Татар халык авыз иҗатында агач исемнәре
11. Татар халык авыз иҗатында кош исемнәре
12. Кушма биологик терминнар һәм аларның төзелеше
13. Татар теленең диалектларында үсемлек атамалары
14. Татарстан Республикасының үсемлекләрне саклау станциясе
15. Татарстан Республикасының экология һәм табигый байлыклар министрлыгы
16. Үсемлек атамаларының фразеологизмнарда кулланылышы.

## 2. КОШЛАР – БЕЗНЕҢ КАНАТЛЫ ДУСЛАРЫБЫЗ
## ПТИЦЫ – НАШИ КРЫЛАТЫЕ ДРУЗЬЯ

---

### Татар телендә сүз төзелеше

### §1. Тамыр һәм кушымча

**Укыгыз һәм истә калдырыгыз!**

Тамыр – сүзнең иң төп (лексик) мәгънәсе саклана торган кисәге. Татар телендә һәрбер тамыр аерым сүз була ала һәм ул билгеле бер сүз төркеменә керә. Тамырны мәгънәле башка кисәкләргә бүлеп булмый: *эш, яшь, бас* һ.б. Тамыр сүзләр һәм кисәкләр телнең гомуми сүзлек составына караганда азрак була, ләкин ул бик озак, гасырлар буе яши һәм телгә яңа сүзләр тудыру өчен төп база булып тора.

Тамырга ялганып, өстәмә лексик-грамматик һәм абстракт-грамматик мәгънә белдерә торган мәгънәле кисәкләр кушымчалар (суффикслар) дип аталалар. Кушымчалар тамырда белдерелгән мәгънәне тулысынча яки өлешчә үзгәртеп, аның төп мәгънә эчтәлеген төрлеләндерергә хезмәт итәләр яки сүзнең нигезендәге мәгънәсен үзгәртмәстән, аңа нинди дә булса бүтән мәгънә төсмерләре өстиләр. Кушымчалар белән сүз ясау яисә төрләндерү татар телендә киң таралган һәм татар теленең агглютинатив тел булуын билгели. Мәсәлән: *эш – эшлә, эшчән, эшсезлек; яшь – яшьлек, яшьләй, яшел, яшәр; бас – басма, баскыч, баскын* сүзләре арасында, югарыда әйтелгәнчә, *эш, яшь, бас* сүзләре – тамыр, калганнары исә - шул тамырларга кушымча ялганып ясалган бөтенләй яңа мәгънәле аерым сүзләр. Шушы ук тамырларга кушымчалар ялганудан килеп чыккан *эштән, эшне, яшьрәк, яшьләр, баскан, басса* сүзләрендәге кушымчалар төп мәгънәгә аз гына үзгәреш кертеп, сүзнең төрләрен, формаларын гына үзгәртәләр.

**1. Биремнәр.**

1.Текстны укыгыз һәм аңа исем бирегез. 5-6 җөмлә ярдәмендә эчтәлеген сөйләгез.
2.Калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрне кулланып, диалог төзегез.
4.Тексттан тамырдан гына торган кушымчасыз сүзләргә һәм тамыр белән кушымчадан торган сүзләргә унар мисал язып алыгыз. Мәсәлән: *өч* – тамыр сүз, *галим-**нәр*** – тамыр һәм кушымчадан торган сүз.

Галимнәр исәпләвенчә, Татарстан территориясендә җәен кошлар өч йөзгә якын төре яши икән. Ә элекке Союзда ул 800 төр исәпләнгән. Безнең республикада утрак рәвештә яшәүче алтмышлап төр кош барлыгы билгеле. Аларга төрчәләрен дә кертсәк, бу сан күпкә артачак.

Һәр тереклек, шул исәптән кошлар да, Җир йөзенең теге яки бу өлкәләре, районнарының табигать шартларына яраклашканнар. Билгеле, алар арасында утраклыкны вакытлыча алыштыручылары да аз түгел. Шундыйларга күчмә кошлар керә. Ә менә **ала карга, саескан, чыпчык, песнәк** һ.б. утраклар.

Кошларның берәүләре – урманда, икенчеләре – болын-кырларда, өченчеләре сулыкларда яшәү һәм үрчү өчен яраклашкан. Безнең урманнарда яшәүче кошлар арасында **утрак купшыл** бар. Чыпчык кадәрле бу кошчыкка юкка гына шундый исем бирмәгәннәр. Табигать аңа күзләрне

камаштырырлык төс-бизәкләр биргән. Безнең якның җәйге кунагы **шәүлегән** (яңгыр теләнчесе) – алтын-сары, кыштума яшькелт-зәңгәр “күлмәк”ләре белән кешене сокландырсалар, купшыл исә, маңгае һәм түше кызгылт-көрән, канатлары сары, каралы-аклы төсләре белән һәркемне үзенә җәлеп итә. Купшыллар туклану ягыннан талымсызлар – урманда агач, кырда **тигәнәк**, **алабута** орлыклары белән тукланалар. Алар үзенчә җырлаган да булалар.

Кыштуманы башка кошлар белән бутавы кыен. Аның биләмәсе – инеш, кечкенә елгалар. Ул , ярда оялап бала чыгарса да, көннәре суда маймычлар аулап уза, су төбендәге бөҗәкләрне тота. **Кыштума** – су кошчыгы. Шул тирәлеккә яраклашкан ул. Томшыгы зур һәм без кебек очлы, койрыгы бик кыска, аяклары кыска һәм таза. Бу кош кышкы салкыннардан курыкмый.. Елга-инешнең боз белән капланмаган урыннарында сай суга чумып, су астыннан йөгереп, үзенә азык таба. Аксыл-сары түшле, коңгырт-карасу төсләргә манчылган су чыпчыгы да, кыштума кебек, елга-инеш буйларында яши, судагы тереклек белән туклана.

| | |
|---|---|
| **купшыл –щеголь** | **төрчә – подвид, подкласс** |
| **күчмә – перелётный** | **утрак - оседлый** |
| **кыштума – зимородок** | **безтомшык - шилоклювка** |

**2.Биремнәр.**

1**.** Күпнокталар урынына текст ахырында тәкъдим ителгән таблицадагы сүзләрне куеп, текстның эчтәлеге белән танышыгыз..

2. Текст ярдәмендә сорау кисәкчәләре һәм “әйе”, “юк” сүзләрен кулланып, диалог төзегез, диалогны тиешле интонация белән укыгыз.

3. Сүзләрне тиешле баганаларга урнаштырыгыз һәм таблицаны күчереп языгыз.

Чәүкә - безнең шәһәр һәм авылларда очрый *тамыр +форма ясагыч* иң гадәти *тамыр сүз*. Алар - кышын китми торган *тамыр+ форма ясагыч*. *Тамыр+тамыр* урыннарда гына алар кышын 200-300 километр көньяккарак күчә. Язын чәүкәләр үз ояларына кире *тамыр+ясагыч+форма ясагыч* кайталар да агач куышы, чормалардагы ояларын *тамыр+ясагыч+форма ясагыч* керешәләр. Аларга бер *тамыр сүз* берничә елга җитә. Иске ояларын рәтләгәч, яки, кирәк булса, яңасын *тамыр+форма ясагыч, тамыр сүз* чәүкәләр карасу бөрчекле *тамыр+тамыр* 3-8 йомырка сала. 16 тамыр + *форма ясагыч* вакыт узганнан соң, ул йомыркалардан балалар чыга. Азыкка килгәндә, чәүкәләр талымлы түгел. Кайчакларда, *тамыр+тамыр, тамыр + ясагыч* бакчаларын “басалар”, ләкин, күбесенчә *тамыр+ясагыч* ташландыкларны ашап, “шәһәр санитарлары” вазифасын башкаралар. Әмма чәүкәләрнең төп файдалары: алар корткыч бөҗәкләрне – май коңгызын, фил коңгызын, яфрагашарларны *тамыр+ясагыч* юк итәләр.

| Тамырдан гына торган сүз | Тамыр+яс. кушымча | Тамыр + фор. яс. кушымча | Тамыр+яс.+фор.яс. кушымча | Тамыр+тамыр |
|---|---|---|---|---|
| рәтләргә<br>күпләп<br>торган | кош<br>җиләк-җимеш<br>әйләнеп | кайбер<br>ана<br>төзегәч | кошлар<br>төрле<br>яшькелт-зәңгәр | көнләп<br>яшелчә<br>оя |

## §2.Татар телендә кушымча төрләре

**Укыгыз һәм истә калдырыгыз!**

Төп функцияләре ягыннан кушымчалар яңа сүз яки бары тик грамматик форма гына ясауларына карап, сүзьясагычка һәм грамматик(мөнәсәбәт белдерүче) кушымчаларга бүленәләр. Грамматик кушымчалар үз чиратында ике төркемгә бүленәләр.

Билгеле булганча, грамматик кушымчаларның бер өлеше җөмләдә турыдан-туры сүзләрне бәйләү өчен хезмәт итә, шуңа күрә аларны сүз бәйләүче (бәйләгеч) кушымчалар дип атыйлар. Аларга тартым, килеш, хәбәрлек, зат-сан кушымчалары керә.

Грамматик кушымчаларның икенче төре бер сүзне икенчесенә бәйләү өчен хезмәт итми, ә нинди дә булса морфологик форма ясый һәм чынбарлыкка мөнәсәбәтне ачыграк күзалларга ярдәм итә. Аларны форма ясагыч яки модаль кушымчалар дип йөртәләр. Кушымчаларның бу төрен исемнәрдә күплек сан кушымчалары, сыйфатларда чагыштыру һәм кимлек кушымчалары, рәвешләрдә чагыштыру кушымчалары, саннарда төркемчә һәм фигыльләрдә юнәлеш, дәрәҗә, юклык, заман кушымчалары тәшкил итә.

Кушымчалар нигезгә ялганганда яңа сүз ясамасалар һәм грамматик мәгънә дә белдермәсәләр, сүзнең бары стилистик төсмерен генә үзгәртсәләр, андыйлар стилистик кушымчалар дип аталалар. *–чык/-чек* (кыз*чык*, мәйдан*чык*, шәһәр*чек*) һәм *кай/-кәй* (*-каш/-кәш*) кушымчалары шундыйлардан.

Яңа лексик мәгънәгә ия яңа сүз ясый торган кушымчалар сүзьясагычлар дип аталалар. Ясагыч кушымчалар бер үк тамырга ялганып та төрле мәгънәгә ия яңа сүзләр ясый алалар, бер үк тамырдан ясалган сүзләрне тамырдаш сүзләр дип йөртәләр.

**3.Биремнәр.**

1.Текстны укыгыз, эчтәлеген сөйләргә әзерләнегез.

2.Карга белән козгынның уртак һәм аермалы яклары турында диалог төзегез.

3.Тексттан бер һәм ике тамырдан торган сүзләргә өчәр мисал язып алыгыз, асларына сызылган сүзләрнең схемаларын төзегез. Үрнәк*: чүлләрдә*: Т+ФЯ+Б.

Козгын белән карганы бутамаска кирәк. Алар төрдәшләр генә, хәтта аларны тышкы кыяфәтләр буенча да аеру җиңел. Козгын – бик сак кош һәм кешедән читтәрәк булырга тырыша. Аның күзе үткен, үзе бик яхшы ишетә. Ул төньякта да эссе чүлләрдә дә яши, кырыс табигатьле, 4 мең метрдан биегрәк яссы таулык табигатенә дә җайлаша ала. Гарәпләр козгынны мәңгелек кош дип исәпләгәннәр, борынгы заманда аны өч йөз ел яши дип уйлаганнар. Чынында ул 70-75 ел яши. Козгын төрле азык: җиләк-җимеш, ашлык, төрле үлән-яфраклар ашый, кош ояларын туздыра, хәтта акчарлак кебек зур кош йомыркаларын, яңа чыгарган бәбкәләрен дә урлый. Ул кимерүчеләрне бик оста аулый, үләксәләрне, авыру һәм бөтенләй хәлсез хайваннарны юк итә – нәкъ санитар. Кызганычка каршы ул сирәк очрый, Европаның күп урыннарында аны бөтенләй кырып бетергәннәр. Хәзер инде аны саклап калу чараларын күрәләр.

**Бу кызык!**

**Чәүкә “галка” –** диал. *чаука*, карачай-балкар т. *чаука,* удмурт, коми т. *чавкан* (татарчадан булса кирәк) чаука,чәүкә – чәүкәләрнең тавышыннан чыгып ясалган сүзләр. *Чау-чау* – чәүкәләр тавышы (чау+-ка – чәү+-кә).

**4.Биремнәр .**

1. Шәүкәт Галиевнең “Камыш тургае”шигырен сәнгатьле итеп укыгыз.
2. Шигырьнең эчтәлегеннән ниләр аңладыгыз? Ни өчен тургай сагышлы?
3. Курсив белән бирелгән сүзләрнең тамырларын аерып алып, дәфтәрләрегезгә язгыгыз, аларга башка ясагыч кушымчалар ялгап, яңа сүзләр ясап карагыз.
4. Киләсе дәрескә шигырьне яттан сөйләргә өйрәнеп килегез.

Бала чыгара камыш тургае.
*Тәмле* хыялы, татлы уйлары:
“Матурым-турым” үземә охшар,
Үземчә сайрар, *үземчә очар*!”
Тиз үсте *кошчык*, әмма ят никтер...

Син аңа ташып җим генә җиткер!
“Ку-ку” диюен *ничек* аңласы –
Ят ана *исемен* әйтә баласы?!
Бала *үстерде* камыш тургае,
Хәзер инде ул сагыш тургае...

(Шәүкәт Галиев).

**5.Биремнәр.**

1. Текстны укыгыз һәм төп эчтәлеген 5-6 җөмлә белән сөйләп бирегез.
2. Курсив белән бирелгән җөмләләрне сорау җөмләләргә әйләндерегез.
3. Асларына сызылган сүзләрне төзелеше буенча тикшерегез. Үрнәк*: төрдәшләр – төр – тамыр; -дәш – ясагыч кушымча, -ләр –форма ясагыч кушымча, нигез – төрдәш.*

Козгын белән карганы бутамаска кирәк. Алар төрдәшләр генә, хәтта аларны тышкы кыяфәтләр буенча да аеру җиңел. Козгын – зур кош. *Гәүдәсенең озынлыгы 66 сантиметрга җитә*. Каурыйлары кара төстә, калын, ялтырап тора. Карга исә кечерәк. *Шуны да әйтергә кирәк: каргаларның барысы да кара булмый.* Аларның башы, канатлары, койрыклары гына кара, ә гәүдәләре көлсу-соры төстә була, шуңа күрә аларны ала карга диләр. *Ала каргалар Төньяк Европада – Скандинавиядә, Төньяк Америкада, СССР да көнбатыш чикләрдән алып Енисей елгасына кадәр яшиләр.* Ә Енисейдан ары инде кара карга биләмәләре китә. Алар бөтен Азиядә һәм Европаның көньяк-көнбатышында яши. Кара карга белән ала карга “биләмәләре” чикләрендә исә бу каргалар икесе дә һәм аларның катнаш токымнары да очрый. Каргалар үзләреннән зуррак гәүдәле туганнары - козгыннан куркалар һәм аңа көтүләре белән һөҗүм итәләр.

**ала карга – ворона** **козгын - ворон**
**биләмә - владение** **кыяфәт- внешность**
**кара карга – грач** **токым –порода**
**һөҗүм итү – нападать** **туганнар - сородичи**

**Бу кызык!**

**Шәүлегән –**“иволга” – тат. диал. шүлегән “ оляпка” (су астына төшеп корт чүпли ала торган кош) – тат. диал., башк. *шүлгән* “су асты патшасы”, рус. *шуликун, шулейкун*, мар. *шулейкин*, якут. *сүлүкүн* “Яңа ел төнендә су астыннан чыга торган явыз рух”, кытай. *шуй-луң-хуан* “су аждаһалары патшасы” сүзеннән булса кирәк (ул аждаһа кайчак кошка әверелеп күккә аша имеш). *Шүлгән* – башкорт эпосында еш очрый торган персонаж. “Заятүләк” дастанының бер вариантында ул – Сусылуның атасы. Шуңа охшаш әкияти каһарман Тувада *Шулугун* дип атала. Бу вариант тат. *шолган, шуылган, шыулыган* “су күсесе” сүзен дә әлеге аждаһалар патшасы исеменнән дип уйларга нигез бирә.

## §3.Татар телендә сүзнең нигезе

**Укыгыз һәм истә калдырыгыз!**

Сүзнең төп мәгънәсен тамырда һәм тамырның мәгънәсенә үзгәреш кертә торган кушымчалар төзелмәсендә саклана. Шуңа күрә сүзнең тамыры аның мәгънәсенә үзгәреш кертүче ясагыч кушымчалары һәм элементлары белән нигез дип атала. Нигездән соң килгән һәм аның мәгънәсенә бернинди үзгәреш кертми торган кушымчаларны төрләндергечләр дип йөртәләр. Аларга килеш, тартым, зат-сан кушымчалары һ.б. керә.

Шулай итеп, нигез ике төрле була: тамыр нигез һәм ясалма нигез.

Тамыр нигез, үз мәгънәсен саклаган хәлдә, хәзерге татар телендә морфемаларга бүлгәләнмәве, ягъни бу яктан да тоташ бер бөтен булуы белән аерыла. Анда сүзнең иң төп, иң үзәк мәгънәсе саклана. Шуңа күрә аны тамыр дип кенә атыйлар. Тамыр нигез тарихи яктан тагын да борынгырак, фонетик төзелеш ягыннан чагыштырмача кечерәк күләмдә була. Тамыр нигезнең күпчелеге бер яки ике иҗектән тора.

Ясалма нигез, тамыр нигездән аермалы буларак, үз төзелмәсе эчендә морфологик бүлгәләнә дә ала. Ул мөстәкыйль нигезләргә я мөстәкыйль тамыр белән ясагыч кушымчаларга аерыла. Мәсәлән: *тора+-к, сыз+-ым, ак+кош, көн+озын*. Шулай итеп, ясалма нигез я аерым нигезләрнең үзара кушылу юлы белән, я тамырга ясагыч кушымчалар ялгану юлы белән ясала. Ясалу алымнары буенча, ясалма нигезләр ике төргә аерылалар: кушма нигез, ясагычлы нигез.

**6. Биремнәрне үтәгез.**

1. Күпнокталар урынына тиешле ясагыч кушымчаларны куеп, текстны укыгыз.
2. Өч төркемгә бүленегез. Суер, көртлек, боҗыр турында укытучы биргән карточкаларны җыеп(карточкада бер генә җөмлә), әлеге кошларның берсе турында текст төзегез һәм көндәш төркемнәргә үз текстыгыз буенча сораулар әзерләгез.
3. Текст ярдәмендә диалог төзегез, аны тиешле интонация белән укыгыз.
4. Кушма нигезле сүзләргә мисаллар язып алыгыз, алар ярдәмендә сорау җөмләләр языгыз.

**Суер, көртлек, боҗыр**

Бу кошлар ояларын җиргә һәм агач башларына ясый, алар үзләре дөньяга килгән урыннан ерак очмыйлар. Буран....(сыйфат ясагыч) кышларда кичен, караңгы төшкәч, агач башыннан кар көртенә төшеп, шунда төн куналар. Бу кошлар май ахыры июнь башында бала чыгара. Йомыркаларын җирдәге чокырга салалар, шунда мүк, вак чыбык-чабык, кош каурые ташыйлар. Йомырка өстендә тавык кебек, өч атна утыралар. Аларның яраткан азыклары җәен – каен җиләге, кура җиләге; көз...(рәвеш ясагыч) – нарат җиләге, үлән орлыклары. Кыш көне агач бөреләре, нарат, эрбет һәм артыш чикләвеге белән тук....(фигыль ясагыч)алар. Җәйге эссе көннәрдә, бөҗәкләрдән котылу өчен, комда коеныrга яраталар.

Бу кошларның гәүдәләре нык, канатлары кыска, киң. Аяклары тиз йөгерү өчен җайлашкан, бармаклары дүртәү, томшыклары кыска, юан, бераз кәкре. Ярыйсы гына очалар, ләкин дошманнарыннан йөгереп качуны артыграк күрәләр. Әлеге кошлар төзелешләре белән бер-берсенә охшамаган. Суер – зур кош: карт әтәчләре 5-6 кг га җитә. Бездә аннан да зур кош юк. Ата суер бик матур. Аның муены һәм башы кара тимгел төшкән куе соры төстә, тамак асты кара-яшькелт ялтыравыклы, түше һәм тамагы коңгырт-кара, карасу төстәге корсагы ак тимгелле. Томшыгы алсу-соры, язын күз өстендә кызыл мамык каш чыга. Иягендәге каурыйлары озын: сакал төсле.

Ана суер тутык һәм ак тимгелле аркылы юллар төшкән ачык көрән төстә. Агач ботаклары һәм корыган яфраклар арасына ясаган оясында утырганда ул күренми дә. Ана суер, язын үзенең җырын җыр... (фигыль ясагыч)ганда бернәрсә дә ишетми. Шуңа аны руслар "глухарь" (саңгырау) дип атаганнар да.

Көртлек суердан кечкенә. Ата көртлек сумаладай кап-кара, күксел ялтыравыгы бар, күздән өстәрәк кызыл каш, томшыгы кара, канат аслары ак. Ана көртлек кара-коңгырт юллы җирән-чуар төстә.

Боҗыр күгәрченнән аз гына зуррак. Ул бик чуар: соры җирлеккә кара,көрән, җирән ак тимгелләр һәм юллар төшкән. Койрыгы кыс...(сыйфат ясагыч), очы түгәрәкләнеп килгән. Баш түбәсендә селкенеп торган каурый тотымы бар. Ана боҗыр тоташ соры-чуар. Боҗырлар кыш буе парлашып яши. Ә инде язын ана боҗыр оясына утыргач, ата боҗыр аның тыныч...(исем ясагыч)ын саклый.

**боҗыр –рябчик**
**каурый - перо**
**көртлек - тетерев**
**суер – глухарь**
**тимгелле - пятнистый**
**ялтыравык - блеск**

**7.Биремнәр.**

1. Текстны татарчага тәрҗемә итегез.
2. Текст ахырындагы сорауларга татарча җавап бирегез.
3. *Берөзлесез, бәхетле, шарсыман, оялый, корылма* кебек сүзләрнең текстан тәрҗемәләрен табыгыз һәм сүзлек дәфтәрләрегезгә күчереп языгыз, аларның ясагыч һәм кушма нигезле булуларына игътибар итегез.

Ласточка городская - это маленькая птичка, которая прилетает к нам в конце весны - начале лета из далекой Африки, Индостана и Индокитая, а также Малайских островов. Распространена птица в Европе, Азии, на Сахалине, Японских и Курильских островах. Отличает ласточку от других птиц черный шелковый фрак, белая грудка и острый раздвоенный хвост. Это ловкая, изящная птица, беспрестанно парящая в воздухе, способная на лету напиться и даже на мгновение окунуться в воду. Ласточка гнездится в долинах горных рек, где селится в каменистых пещерах и расселинах скал, реже в норах. Большинство ласточек, приспособленных к жизни в городах и больших селах, селится под балконами и крышами зданий. Гнездо этой птицы - аккуратное сооружение шарообразной формы из соломы, глины и земли. После постройки гнезда у счастливой молодой пары в скором времени появятся птенцы, основную пищу которых составляют насекомые. Именно к моменту их появления и прилетают к нам взрослые ласточки. С появлением первых холодов ласточки улетят к далеким берегам.

1.Где распространена и где зимует ласточка городская?

2.Какими словами можно описать ласточку?

3.Почему ласточка городская прилетает к нам из теплых краев достаточно поздно, а улетает, наоборот, рано?

**8.Биремнәр.**

1. Сүзлекчәдән (51-55 битләр) түбәндәге кош атамаларының русча тәрҗемәләрен табып, сүзлек дәфтәрләрегезгә язып алыгыз, аларны истә калдырыгыз.
2. Тамыр нигезле сүзләрне беренче баганага, ясагыч һәм кушма нигезле атамаларны икенче, өченче баганаларга язып төшегез.
3. Кушма нигезле кош атамаларын кулланып, 7-8 җөмләдән торган монолог төзегез.
3. Тәкъдим ителгән кошлар арасыннан үзегезгә ошаган икесенең рәсемнәрен алып килегез (үзегез ясасагыз да була) һәм рәсемгә карата алтышар сорау әзерләгез.

*Бабакош, карлыгач, туктан, каратүш, чебенкош, лачын, тукыр, чукыр, чыпчык, кашыктомшык, ябалак, сыерчык, безкойрык, саескан, чәүкә, аккош, карчыга, песнәк, кызылтүш, челән, безтомшык, күгәрчен, су тавыгы, тутый кош, һөдһөд, тургай, чүкечбаш, тавис кошы, тавә кошы, аккорсак, карчыга.*

**9.Биремнәр.**

1. Текстны татарчага тәрҗемә итегез һәм эчтәлеген сөйләгез.
2. Текстның эчтәлеге буенча җиде-сигез сорау әзерләгез.
3. Тамыр, ясалма һәм кушма нигезле сүзләргә бишәр мисал язып алыгыз.

Стрижи - птицы небольших размеров с плотным телосложением и довольно крупной головой. Широкий и короткий клюв сплюснут сверху вниз, большой разрез рта заходит за глаза, защищенные плотными короткими перышками. Заостренные и длинные крылья в полете саблевидно изогнуты. Короткий и вырезанный на конце хвост бывает прямо срезанным или вильчатым, как у ласточек. У стрижей очень маленькие и слабые ноги, они совершенно не приспособлены к хождению по земле. На лапке находится четыре пальца.

Язык у птиц треугольный и короткий. Во рту расположены многочисленные слюнные железы, которые в период гнездостроения выделяют клейкий секрет. Стрижи собирают материал для гнезда в воздухе. Вообще вся их жизнь проходит в полете. Если птица оказывается на земле, по которой она с трудом ползает, значит у нее возникли какие - то проблемы.

По внешнему виду стрижи очень схожи с ласточками и не сведущие люди их часто путают. Летают они прямо и стремительно. В полете издают громкие визжащие звуки.

В период гнездования строят гнезда в норах, дуплах и пещерах, в постройках людей. Птенцы появляются на свет голыми и слепыми. У тех видов, которые строят свои гнезда открыто, птенцы вылупляются покрытые густым эмбриональным пухом белого цвета. В семействе стрижов насчитывается 69 видов, которые относятся в восьми родам.

**Бу кызык!**

**Карлыгач –** “ласточка” – кара нигезенә төрки сүз *чигай* “кош” кушылудан килеп чыккан. Казакъ т. *карлыгаш*, үзбәк т. *калдиргоч,* төрек т. *карлаңгыч*, чыгтай т. *карачыгай,* тува т. хара ачыгай (чыгай – “лачын”), якут т. *хараңачык*, бурят т. *хараасгай*.

**Чукыр** “клест” – *чукы-у* фигыленнән: башта кошны “чукыр борын, келәшчә борын” дип атаганнар, соңыннан *чукыр* калган. Каракалпак телендә *шокыр* – “өтерге, келәшчә”.

## Дүртенче тема. Кушма һәм ясагычлы нигез

**Укыгыз һәм истә калдырыгыз!**

**Кушма нигез** составында ике һәм берничә тамыр яки нигез катнашкан булырга мөмкин. Андагы сүзләр, тезү яки иярту юлларының берсе белән үзара бәйләнешкән булалар. Мәсәлән *көнчыгыш* (көннең чыгышы), *балалар бакчасы* (балаларның бакчасы) үзара иярту юлы белән, ә *ир-егет* кебек кушмалар тезү юлы белән ясалганнар. Кушма нигезләрне синтаксик бәйләнешләре ягыннан сүз тезмәсенә охшый, әмма хәзерге семантик табигате буенча ул аерым бер сүзне, нигезне тәшкил итә. Чөнки кушма нигез составындагы аерым сүзләр яңа бер төшенчә нигезендә берләшеп, кайберләре үзләренең семантик аерымлыкларын югалталар яки бик нык кечерәйтәләр.

**Ясагычлы нигез.** Ясагыч кушымчалар ясалма нигезнең ясагычлы нигез дип аталган төрен формалаштыручылар буларак, тамырга турыдан-туры яки бер-бер артлы ялганып, аның мәгънәсен дә, морфологик төзелешен дә үзгәртәләр. Төзелеше ягыннан ясагычлы нигез тамыр һәм бер ясагыч кушымчадан яки бер-бер артлы ялганып килгән берничә ясагыч кушымчадан торырга мөмкин: *сер, сер+-ле, сер+-ле+-лек, сер+-ле+-лән, сер+-дәш, сер+-дәш+-лек, сер+-ләш* һ.б. Татар телендә, нигездә, тамырдан соң башта ясагыч кушымчалар, аннары модальлек, сүз ахырына таба бәйләгеч кушымчалар ялгана: *кул-лан-ма-ган-сыз, күрә-к-ләр-не* һ.б. Әмма кайбер сүзләрдә кушымчаларның ялгану тәртибе бүтән төрле дә була ала. Мәсәлән: *көндәлек, белешмә, табылдык* һ.б. Мондый сүзләрнең нигезе соңгы ясагыч кушымча чиге белән билгеләнә.

**10. Биремнәр.**

1. Текстны татарчага тәрҗемә итегез һәм кыскача эчтәлеген сөйләргә әзерләнегез.
2. “Күренекле орнитолог» конкурсына кош исемнәреннән торган кроссворд төзеп килегез.
3. Үзегез белгән һәм тексттагы мәгълүматларга нигезләнеп, “Орнитология фәне” дигән темага диалог төзегез.

Орнитология - отрасль зоологии, изучающая птиц, их эмбриологию, морфологию, физиологию, экологию, систематику и географическое распространение. Термин *орнитология* введён итальянским натуралистом У. Альдрованди в конце 16 века.

Первое сочинение по орнитологии принадлежит Аристотелю (4 в. до н. э.); в его труде «История животных» говорится о 170 видах птиц. В средние века Фридрих II Гогенштауфен в трактате «Об искусстве охоты с птицами» (написан около 1247, напечатан в 1596) дал много сведений о птицах. Во 2-й половине 16 и начале 17 вв. появились сочинения французского натуралиста П. Белона, швейцарского - К. Геснера и итальянского - У. Альдрованди, суммирующие сведения по орнитологии того времени. В 1713 была опубликована классификация птиц, разработанная английским биологом Дж. Реем. Основы современной научной номенклатуры и классификации птиц заложил К. Линней в своей «Системе природы» (1 изд., 1735). В 17-18 вв. исследования птиц распространились далеко за пределы Европы, и Ж. Бюффон опубликовал первый в истории Орнитологии обзор мировой орнитофауны (т. 1-10, 1770-86). Чисто описательные работы по морфологии, систематике и географическому распространению птиц преобладали в Орнитологии до середины 19 в., когда 1564 появилась работа Ч. Дарвина о галапагосских вьюрках и была создана

теория эволюции органического мира (1859), стимулировавшая интерес к исследованиям по сравнительной морфологии и филогении птиц.

**11. Биремнәр.**

1.Тексттан түбәндәге төркемнәргә 7-8 мисал язып алыгыз:

а) бер иҗекле тамыр сүзләр: ә) ике иҗекле тамыр сүзләр: б) тамыр һәм ясагыч кушымчадан торган сүзләр: в) ике тамырдан торган сүзләр:

2. Текстның эчтәлеге белән танышыгыз һәм текст ахырындагы сорауларга җаваплар языгыз.

Кызылтүш – башка кошлар арасында иң матур сайраучы. Аның чут-чут итеп яңгыратып сайравын урман аланында да, шәһәр паркында да, бакчада да ишетергә мөмкин.

Язын кызылтүшләр, парлашып, агачка оя ясый башлый. Бу кошлар гаҗәп осталар: кәрзингә охшатып, мүктән, нәзек чыбыктан, үләннән бик пөхтә итеп ояларын үрәләр. Шуңа күрә агачка яки куакка тырышып яшерелгән ояны тәҗрибәле күз генә аера ала. Әгәр кызылтүш оясын күрсәгез, аңа кагылмагыз, югыйсә, кошлар ояны ташлап китәләр. Тырыш кызылтүшләр җәй буе урманны корткыч бөҗәкләрдән чистарталар. Җәй ахырларында, балалары үсеп җиткәч, кызылтүшләр көтү булып җыелалар да көньякка очып китәләр. Алар безнең кышкы айларны еракта – Төньяк Африканың җылы яр буйларында яки Европаның көньягында үткәрәләр.

Кызылтүшләр утрак кошлармы? Алар оя ясый беләләрме? Кызылтүш матур сайрыймы? Кызылтүшләр кайда яшиләр? Кызылтүш оясына тияргә ярыймы? Ни өчен?

**кызылтүш- зяблик** **үрәләр – плетут**
**тәҗрибәле – опытный** **югыйсә – иначе, а то, в противном случае**
**корткыч бөҗәкләр – вредители (о насекомых)**

**12.Биремнәр.**

1.Түбәндәге сүзләрнең тамырдаш булганнарын парлап язып чыгыгыз.

2. Терек табигатькә караган терминнар белән җөмләләр төзегез.

Керем, кереш, керлелек, керпе, керсезләнү, керән, керәшә,
Кыска, кыса, кысан, кыскартма, кыскыч, кыскача, кысла, кыстыргыч;
Күрексез, күргәзмә, күркә, күренекле, күренеш, күрәгә;
Очкыч, очлап, очсыз, очкалак,очучы, очраклы, очлы, очла;
Төргәк, төргеч, төркмән кушаягы, төркемләү, төркемчә, төрләнеш, төрлелек.

**Бу кызык!**

**Чыпчык** “воробей” – кечкенә кошлар авазына охшатудан килеп чыккан, *чип, чып* “кечкенә кош, чеби, чыпчык” сүзеннән (чып-чык), бор. төрки: *чыпчук, чупчук*, чыгтай: *чимчик*, якут: *чичаг, чычаг* – “кечкенә кош”.

**Чыпчыксыманнар** – кошлар классыннан бер отряд. Евразиядә яшәүче кошларның күпчелеге шушы отрядка керә – 700 дән артык төре һәм кече төрләре бар. Татарстанда 108 төре очрый. Вак төрләреннән тургайлар, чыпчыклар, песнәкләр, карлыгачлар, миләш чыпчыклары, чагыштырмача зуррак төрләре – козгын, ала карга, кара карга.

## Татар телендә сүзләрнең лексик мәгънәсе

**Укыгыз һәм истә калдырыгыз!**

Телнең сүзлек составында бер генә мәгънәгә һәм берничә мәгънәгә ия булган сүзләр аерылып тора. Сүзнең төп мәгънәсе әйберне турыдан-туры, башка мәгънәләрне күз алдында тотмыйча чагылдыра: китап, алма, кояш, һава һ.б. Сүзнең төп мәгънәсеннән тыш өстәмә мәгънәләргә ия булуы аның күпмәгънәлелеге (грек – polis –күп) дип атала.

Сүзнең беренчел мәгънәләрен туры мәгънәләр дип тә йөртәләр. Алар чынбарлыктагы әйберләрне, күренешләрне, билгеләрне турыдан-туры чагылдыралар. Икенчел мәгънәләрне күчерелмә мәгънәләр диләр, чөнки алар атаманың бер күренештән икенче күренешенә күчү нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр. Мәгънә төрләре: конкрет-абстракт, терминологик, образлы-образсыз мәгънә, эмоциональ – эмоциональ булмаган, синонимик, антонимик, омонимик мәгънәләр һ.б.

## §1. Татар телендә мәгънәдәш сүзләр

**Укыгыз һәм истә калдырыгыз!**

**Синонимия** - грек сүзе (synonymos) – бердәй исем дигән мәгънә аңлата. Мәгънәләре ягыннан тәңгәл яки якын сүзләр **синонимнар** дип аталалар. Әдәби яктан, бер-берсенә якын төшенчәне белдерүче сүзләр яки мәгънәле сүзләр күп була. Синоним сүз яки сүз тезмәләре бер үк төшенчә аңлаталар, сөйләмдә бер үк функция үтиләр. Синонимнар фикерне төгәл, анык һәм җыйнак итеп формалаштырырга мөмкинлек бирәләр, сөйләмне матур яңгырашлы ясыйлар, күренеш һәм төшенчәләрне төрле-төрле мәгънә төсмерләре һәм стилистик бизәкләр белән аңлатып, тасвирлап бирергә ярдәм итәләр.

Синоним сүзләрнең мәгънәләре бер-берсе белән төгәл тәңгәл килми, аларның һәркайсы аерым мәгънә төсмере белдерә: *миһербанлы, шәфкатьле, рәхимле, мәрхәмәтле, кешелекле, олы җанлы* һ.б. Бер үк яки якын мәгънәле сүзләр төркеме синонимик рәт дип атала. Мондый рәттә барлык сүзләрнең мәгънәләрен берләштерә торган доминанта сүз була.

**1.Биремнәр.**

1. Текстны укыгыз, кисәкләргә бүлегез һәр кисәккә исем куегыз һәм эчтәлеген сөйләргә әзерләнегез.
2. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрне синонимнары белән алыштырыгыз һәм әлеге җөмләләрне мы/ме кисәкчәләре ярдәмендә, сорау җөмләләргә үзгәртегез.
3. Курсив белән бирелгән сүзләрне кертеп, җөмләләр языгыз.
4. Текстта очраган тереклек ияләренең берсе турында диалог төзегез.

### Имезүчеләр

Татарстан Җир шарының урта полосасында – җәй һәм кыш була торган өлешендә урнашкан. Безнең территориядә диңгез-океан да, тропик урманнар да юк. Шуңа күрә биредә имезүче хайваннардан китлар, тюлень, морж, дельфиннар, Һиндстан һәм Африкадагы **кебек**, филләр, *юлбарыс*, *арыслан*, жираф, маймыл, зебралар, Австралиядәге шикелле *сумкалы көнгерәләр*, опоссум, йомырка салып бала чыгаручы, ә үзе имезүче ехидна, *үрдәкборыннар* **яшәми**.

Берьюллылар (клоакалылар) – *үрдәкборын*, ехидна һәм проехидна, сумкалы җәнлекләр Австралиядә, Тасмания һәм Яңа Гвинея утрауларында яшиләр. Аларның кайбер төрләрен Көньяк Америкада да очратырга мөмкин. Ә менә опоссумнар Төньяк Америка җирләрен дә үз иткәннәр. *Очкалак этләр* һәм *очкалак төлкеләр*, Африка, Океания тропик урманнарында яшәп, җиләк-җимеш белән **туклананалар**. Бу урманнар *ярыммаймылларның* күп төрле булуы белән **билгеле**.

Кимтешлеләр отрядына караган броненосецлар, *кырмыскаашарлар* һәм иренчәкләр Американың үзәк һәм көньяк җирләрендә яшиләр. Аларның баштагы икесе кырмыска һәм термит белән тукланса, *иренчәкләр* **гомерләрен** агач ябалдашларында **үткәрәләр**, яфраклар, яшь ботак, чәчәк һәм төрле җимешләр белән тамак ялгыйлар.

Дөньяда 15 отрядка караган (маймыллар, ярыммаймыллар, *кулканатлылар, ерткыч җәнлекләр, кимерүчеләр, тактояклылар һәм партояклылар,* үлән ашаучы китлар яки сиреналар, китсыманнар, сумкалылар һ.б.) имезүчеләр бар. Аларның тугызы – элекке союз территориясендә, алтысы безнең республикага туры килә. Шунысын да искәртик: туган як фаунасында, төрләр **саны** һәм биомассасы буенча, күпчелекне кимерүчеләр, аннары ерткыч җәнлекләр, алардан кала к*улканатлыла*р һәм бөҗәк ашаучы имезүчеләр алып тора. Бездә имезүчеләрнең 80 ләп төре яши. Билгеле, алар арасында республикабызның көньяк һәм төньяк җирләренә генә хас тереклек ияләре дә бар, әмма без *бүре, төлке, поши, керпе, селәүсен* кебек җәнлекләрне теләсә **кайсы** төбәктә очратабыз.

**кимтешлеләр – неполнозубые** **партояклылар – парнокопытные**
**кимерүчеләр – грызуны** **тактояклылар – однокопытные**
**кулканатлылар – рукокрылые** **еркыч - хищник**
**берьюллылар (клоакалылар) – однопроходные, клоачные**

**2.Биремнәр.**

1. Текстны укыгыз, тәрҗемә итегез.
2. Үз мәгълүматларыгызны өстәп, текстның эчтәлеген сөйләгез.
3. Тексттан түбәндәге сүзләрнең синонимнарын табыгыз: *адәм, бәндә; ашамлык, калын, әмма, саналалар.*

Рысь — типичный для тайги хищник (длиной до 1 м, массой 8—15 кг) довольно крупных размеров, с гибким телом и коротким хвостом (20—30 см), тупой кончик которого как бы обрублен. Подобно другим диким кошкам у рыси острые когти, длинные ноги с широкими лапами. Между пальцами развиты перепонки, позволяющие передвигаться по глубокому рыхлому снегу, не проваливаясь в нем.

В России рысь встречается в глухих, сильно захламленных перестойных хвойных лесах вплоть до Камчатки и Сахалина, куда она проникла сравнительно недавно. Водится рысь также в Карпатах, на Кавказе и в Средней Азии. Везде она малочисленна.

Основной образ жизни рыси оседлый, но при недостатке корма наблюдаются перекочевки. Главным кормовым объектом для нее являются зайцы-беляки. Кроме того, рысь нападает на куропаток, рябчиков, тетеревов, лисиц, бобров, мелких грызунов, молодняк диких кабанов, косуль, ланей, кабарги, лосей, северных оленей. За один раз она съедает немного пищи, остатки же прячет в укромное место или закапывает в снег.

Рыси считаются вредными хищниками, но все же полного уничтожения не заслуживают, так как они малочисленны, а кроме того, в природе играют такую же роль, как и волки: они губят среди таежных животных главным образом больных, слабых, неполноценных особей.

**3.Биремнәр.**

1. Текстны татарчага тәрҗемә итегез.
2. Текст ахырындагы тиеннәр турында татарча текстның эчтәлеге белән танышыгыз һәм әлеге тексттан алынган мәгълүматларны өстәп, монолог төзегез.
3. Табышмакны укыгыз, җавабын табыгыз**.** Киек-җанварлар турында бер-берегезгә табышмаклар әйтешегез.

*Кош түгел, оча, ябалактан курка,*
*Чикләвекне ярата, сызгырса, урманны яңгырата.*

Белки - типичные лесные зверьки (длина тела 20-30 см, масса - до 1 кг). Из характерных особенностей можно отметить кисточки на концах ушей (более длинные зимой) и пушистый хвост. Благодаря тому что густые волосы, покрывающие хвост, располагаются по бокам, хвост кажется плоским, его длина немного короче длины тела. Когда белки перепрыгивают с дерева на дерево или соскакивают на землю, хвост служит им рулем и парашютом.

Окраска шерсти этих зверьков зависит от сезона года и географического местообитания. Так, например, у восточносибирских и алтайских белок цвет шерсти летом темно-бурый, почти черный, а зимой - темно-серый; у западносибирских и европейских он летом рыжий, а зимой - светло-серый. Летом мех у белок редкий, зимой становится густым. По красоте и качеству меха ценятся выше других серебристо-серые белки-телеутки из сибирских лесов.

Живут белки как в тайге, так и в смешанных и широколиственных лесах, придерживаясь главным образом старых массивов, богатых кормами. В хвойных лесах они питаются семенами шишек и кедровыми орешками, а в лиственных - желудями, орехами бука и лещины. Кроме того, белки поедают различные ягоды и грибы, цветочные почки, фрукты, ловят садящихся на деревья жуков и бабочек, а при случае разоряют птичьи гнезда, выпивая яйца и поедая птенцов. При неурожае шишек зимой они едят побеги и почки деревьев, нежную кору кустарников, разыскивают кладовые бурундуков и кедровок, используя их содержимое. Сами белки тоже делают запасы кормов: прячут орехи в лесной подстилке, закладывают грибы за отставшую кору деревьев или укрепляют их на развилке ветвей. Так делают все белки, поэтому при недостатке кормов любая из них может воспользоваться этими

запасами. Тонкое обоняние позволяет белкам обнаружить корм, даже если он засыпан снегом.

В холодное время белки прячутся в дупла, выдолбленные дятлом, или поселяются в собственных шарообразных гнездах, называемых «гайно». Каждая белка обычно устраивает несколько подобных убежищ. Сначала она сплетает из толстых веток и прутьев основание гнезда, затем возводит бока, а сверху делает крышу. Внутри гнездо выстилает мхом, лишайником, сухими травинками, листьями, липовым мочалом, шерстью и другими материалами. Получается мягкая подстилка. В гнезде делается один или два выхода, которые зимой в сильные морозы белки затыкают мягким лишайником.

Тиен – безнең урманнарда, бигрәк тә ылыслы урманнарда, еш очрый торган җәнлек. Билгеле, соңгы 10-20 елда аларның саны бик нык кимеде. Чыршы һәм нарат күркәләре уңышы булмаган елларда тиеннәр йөзләрчә чакрым ераклыктагы ылыслы урманнарга күченәләр. Җәй көннәрендә алар җиләк, гөмбә, төрле үлән белән тукланалар, хәтта чикләвек уңган елларны кышка җыеп калдыралар. Шунысы да билгеле, тиен, җәен-көзен гөмбәләрне агач ботакларында киптереп, аларны кышлыкка әзерли.

**4. Биремнәр.**

1.Текстны укыгыз, тәрҗемә итегез.

2.Калын хәреф белән бирелгән сүзләрне мәгънәдәш сүзләре белән алыштырыгыз һәм җөмләләрне дәфтәрләрегезгә күчереп языгыз.

3.Текст ахырындагы таблицаны тутырыгыз.

Керпе начар күрми, **ләкин** аның төп ярдәмчесе – борыны. Керпе, **ашарга** ярый торган **бөтен** нәрсәнең – бөҗәкләрнең, аларның личинкаларының, әкәм-төкәмнәрнең, лайлач әкәм-төкәмнәрнең исен сизеп, кыска тәпиләре белән бик тиз атлап, җир өстеннән бара. Ул гөмбә, җиләк, үлән, хәтта **кайвакыт** бака да ашый, тычкан ояларын туздыра. Керпе булган **йортта** тычкан **яшәми**. **Тик** ул өйдә дә тыштагы **кебек** төнлә йөри.

Олы керпедә энәнең озынлыгы 2-4 см, юанлыгы 1 мм. Керпенең авырлыгы бер килограммга, буе 30 см га җитәргә мөмкин. Керпе балалары йомшак энәле булып, бик көчсез һәм сукыр килеш туа. Алар 12-25 грамм гына килә. Яңа туган керпеләрнең күзләре ике атнасыз ачылмый, **шул** вакыт эчендә аларның энәләре катылана, кара һәм ак буйлар ясала. Энәләр – керпенең төп саклану коралы. Алар ике айга **кадәр әниләренә** ияреп йөриләр. Өч-дүрт атнадан соң үзләре азык таба башлый.

Керпе көз көне аулак **урынга** коры яфрак һәм үлән ташый. Шар кебек йомарланып, кыш буе йоклый, кайвакыт аның тән температурасы плюс алты градуска кадәр төшә. Ләкин көчле салкыннарда аңа уянырга һәм "җылынырга" туры килә. Моның өчен көз көне тупланган май запасы китә. Шуңа күрә ул салкыннан курыкмый. Кышын җепшек көннәр һәм салкыннар күп булып, аңа еш уянырга туры килсә, керпе җыелган маен артык күп тота һәм язга көчсезләнә. Керпе – бик файдалы хайван, аларны сакларга кирәк.

| **Җөмләләрне укыгыз һәм текстның эчтәлегенә туры килү-килмәвен билгеләгез** | **туры килә** | **туры килми** |
|---|---|---|
| Керпенең авырлыгы 5 килограммга кадәр җитәргә мөмкин | | |
| Бала керпедә 16 меңгә якын энә була. | | |
| Ул гөмбә, җиләк, үлән, хәтта кайвакыт бака да ашый | | |
| Керпенең төп ярдәмчесе – күзе. | | |
| Керпе бака белән тычканнан курка. | | |
| Энәләр – керпенең төп саклану коралы. | | |
| Керпе шар кебек йомарланып, кыш буе йоклый. | | |
| Керпенең тәпиләре бик озын. | | |
| Керпе – бик файдалы хайван, аларны сакларга кирәк. | | |

## §2. Татар телендә капма-каршы мәгънәле сүзләр

**Укыгыз һәм истә калдырыгыз!**

Капма - каршы мәгънәле сүзләр антонимнар (грек. anti – “каршы”, onyma – “исем”) дип аталалар. Антонимнарның үсеше кешенең чынбарлыктагы капма-каршы күренешләрне танып белүенә бәйле: *төче – ачы, ак – кара, керү - чыгу, иртә - кич, салкын – җылы, дус – дошман, ерак – якын, биек – тәбәнәк, симез – ябык* һ.б.

Бөтен сүзләрнең дә антонимы була алмый. Мондый үзенчәлек иң беренче чиратта билге белдергән сүзләргә хас, чөнки иң башлап билгеләр каршы куела: *озын – кыска, күп – аз, туры – кыек, куе – сыек, батыр – куркак, матур – ямьсез*.

Сүз төркемнәре арасында сыйфатлар, рәвешләрнең антонимнары күп. Әйбернең эш-хәл буенча билгесен фигыльләр дә белдерә, шуңа күрә аларның да антонимнары шактый: *керү-чыгу, бару-кайту, ачу-ябу, яшәү-үлү* һ.б. Билге мәгънәсе исемнәрдә дә бар: *караңгылык – яктылык, ут – су, гыйлемлек – наданлык, эч – тыш* һ.б.

**5.Биремнәр.**

1. Текстны укыгыз һәм эчтәлеген сөйләргә әзерләнегез.
2. Тексттан түбәндәге сүзләрнең антонимнарын табыгыз һәм алар белән җөмләләр төзегез: *нечкә, карт, кыска, авыр түгел, хәзер, иске, ата*.
3. Текст буенча биш сорау языгыз һәм төркемдәшләрегез белән әңгәмә корырга әзерләнегез.

Поши – безнең як урманнары пәһлеваны. Мөгезләре дә чатлы-ботлы. Ул мөгезен декабрьдә ташлый. Ике агач кәүсәсенә тыгып каера ул аны. Мартта яңа мөгез үстерә башлый. Май аенда ана поши бер яки ике бозау китерә.

Кешеләр пошины күптән кулга ияләштерергә тырыша. Мәсәлән, Кострома өлкәсенең дәүләт авыл хуҗалыгы тәҗрибә станциясендәге пошилар фермасында (ул Сумароково авылында урнашкан) бу хайваннар белән төрле сынаулар үткәрәләр. Поши кешене шул ягы белән җәлеп итә: ул калын карда да, язгы-көзге пычракта да җиңел йөри, көчле хайван, чыдам да. Елның теләсә кайсы вакытында үзенә азык таба. Ләкин пошиларга кышын җиңел түгел. Аяклары озын булса да, корсаклары белән кар ярып, яшь усаклар утырган куелыкка юнәләләр, агач кайрысы белән тукланалар яки наратлыкта яшь үсентеләрнең башларын өзеп ашыйлар

**6.Биремнәр.**

1. Текстны укыгыз, тәрҗемә итегез.
2. Текст ярдәмендә сорау кисәкчәләре һәм “әйе”, “юк” сүзләрен кулланып диалог төзегез, диалогны тиешле интонация белән укыгыз.
3. Курсив белән бирелгән сүзләрнең антонимнарын табыгыз һәм алар белән җөмләләр төзегез.

Слово дельфин восходит к греческому δελφίς (*delphis*), которое в свою очередь произошло от индоевропейского корня *$g^w$elbh- «матка», «лоно», «утроба». Название животного может быть истолковано как «новорожденный младенец» (возможно, из-за внешнего сходства с младенцем или из-за того, что крик дельфина похож на крик ребенка).

В 1970-х годах группа учёных Утришской морской станции ИПЭЭ (Институт проблем экологии и эволюции имени А.М.Сверцова) открыла у дельфинов необычный характер сна. В *отличие* от других изученных на тот момент млекопитающих, в состоянии медленного сна у них попеременно находится только одно из двух полушарий мозга. Пожалуй, главная причина этого - в том, что дельфины вынуждены время от времени подниматься к поверхности воды для дыхания.

Дельфины очень подвижные и ловкие, прожорливые хищники, живущие в основном общественно, водятся во всех морях, *поднимаются* даже высоко в реки, питаются главным образом рыбой, моллюсками, ракообразными; иногда нападают и на своих сородичей. Отличаются также любознательностью и традиционно *хорошим* отношением к человеку.

**7. Биремнәр.**

1. Текстны укыгыз, эчтәлеген сөйләргә әзерләнегез.
2. Калын хәрефле сүзләрне антонимнары белән алмаштырып, җөмләләрне укыгыз. Текстның эчтәлеге үзгәрдеме? Фикерегезне дәлилләгез.
3. Тексттан ике сүз сайлап алыгыз һәм алар составындагы авазлардан яңа сүзләр уйлап языгыз. *Үрнәк: антилопа – ат, апа, ил, он, ит, ант һ.б.*
4. Текстның эчтәлеге буенча бер-берегезгә сораулар бирегез.

Еш кына, газель кебек зифа яки серна кебек **әкрен** диләр. **Калын** аяклы, тупас муенлы, артык **кечкенә** булмаган газель антилопалар чыннан да бик зифа була. Алар Африка һәм Азия чүлләрендә һәм далаларында **үлә**. Безнең илдә газель җәйрән **бар**. Сайгак антилопа – газель белән чагыштырганда бик **матур**. Аның башы зур, йомшак һәм сизгер борыны кабарып тора, **көчле** мускуллы аяклары **кыска**. Ләкин сайгак дала буйлап сәгатенә 70 км дан артыграк юлны чабып үтә ала! Бездә ул Казахстанда, Түбән Идел далаларында яши. Европа тауларында һәм бездә Кавказда тау кәҗәсе антилопа яши.

Антилопалар күптөрле була: иң зурлары сыер хәтлеләре – Африка антилопасы канна, иң **зурлары** – дики-дики дигәннәре дә Африкада яши, алар куян кадәр генә.

Африкада гну антилопа яши. Аның гәүдәсе һәм койрыгы атныкы кебек, ә куш тояклары һәм мөгезле киң башы үгезнеке шикелле. Ул, карап торышка **җиңел** хәрәкәтле күренсә дә, бик **начар** йөгерә. Күп кенә

антилопаларның мөгезләре гаҗәп **ямьсез** була: мәсәлән, куду антилопаның мөгезләре кылычсыман, орикс антилопаның мөгезләре **кәкре** һәм озын.

**8.Биремнәр.**

1.Равиль Фәйзуллинның "Кызыл китап" шигырен сәнгатьле итеп укыгыз, яттан сөйләргә әзерләнегез.

2.Түбәндәге сүзләрнең антонимнарын текстан табып, дәфтәрләрегезгә парлап язып төшегез. Юк - .......... , Тәүге (беренче) - ............, аз - ......., бирдек - ........, мәгънәсез - ....... , табылуы - ..........., монда ..........

3.Кызыл китап турында диалог төзегез.

4.Кызыл китапка кертелгән берәр җәнлек-җанвар турында татарча презентация әзерләп килегез.

Яшел китап... Бәрхет китап...
Чыкты Кызыл китап та!
Югалуы мөмкин төрләр
Анда барсы хисапта.

Китаплар күп. Бусы – кызыл,
Кызыл төс юкка димә!
Кызыл төс сискәндерә дә,
Кызыл төс: "Тукта!" – ди дә.

Җәнлеге дә, киеге дә,
Үләне, бөҗәге дә...
"Саклап калыйк!" дип куелган
Игътибар үзәгенә.

Димәк, яшәр Җиребездә
Хәлләр бар шомланырлык
Табигатьтән ни алдык та
Аңарга ни калдырдык?

Бар соңгы кат очкан кошлар...
Соңгы чәчәкле гөлләр...
Килер буынга калырмы
Алар рәсемдә генә?

"SOS!" мәгънәле китап ул -
Башы да, азагы да.
Табигать – аның авторы,
Кешеләр - язган гына...

(Равиль Фәйзуллин).

**9. Биремнәр**.

1. Текстны укыгыз. Сүз нинди җәнлек турында бара?
2. Сан кергән җөмләләрне, җәнлекнең исемен куеп, дәфтәрләрегезгә күчереп языгыз.
3. Әлеге җәнлек турында тагын нәрсәләр беләсез? Шул темага диалог төзегез.

.................. – этләр семьялыгындагы ерткыч җәнлек. Аның гәүдәсе 60-90 см, койрыгы 40-60 см, авырлыгы 6-10 кг га җитә. ....................ерткыч җәнлек булса да, төрле ризык ашамый. Аның туклану нигезен кимерүчеләр тәшкил итә. Рационында зуррак имезүчеләр дә була, мөмкинлек чыкканда кошларны да тота, үсемлек ризыклары, җимешләр, җиләкләрдән дә баш тартмый. .............. Куяннар күпләп үлгәндә, аларның үләксәләрен юк итеп, башка җәнлекләргә чир таралудан саклаучы да ул.

.................. елына бер тапкыр балалый. Аның йөклелек чоры 49-58 көн дәвам итә. Ул кайчак 4-6, кайчак 12-13 бала тудыра. ............ табигатьтә җиде елдан артык яшәми, тоткынлыкта аның гомер озынлыгы 20-25 ел тирәсе.

## §3. Татар телендә аваздаш сүзләр

**Укыгыз һәм истә калдырыгыз!**

**Омонимнар** – (грек. homos – бертөрле, onyma – исем) бертөрле аваз составына ия булган , әмма мәгънәләре ягыннан аерыла торган төрле сүзләр. Бу төр сүзләр арасында мәгънә-төшенчә уртаклыгы булмый. Мәсәлән: *сыр* (ашамлык) – *сыр*(сызык), *ай* (утыз көн) – *ай* (күк җисеме), *кала* (фигыль) – *кала* (шәһәр) һ.б.Омонимнарның ясалыш ягыннан түбәндәге төрләре бар: төп (тамыр) яр (елга яры), яр ( сөйгән яр); ясалма омонимнар: алма(боерык фигыль), алма (исем).

Әйтелеш –язылыш ягыннан төрләре:

1) саф лексик – теләсә нинди фонетик, грамматик шартларда аваз составы ягыннан һәм тамыр хәлендә омонимлыкларын югалтмыйлар: *ат* - *ат.*

2) омофоннар – язылышлары төрле, әйтелешләре бертөрле булган сүзләр: *карала – кар ала*.

3) омографлар – язылышлары бердәй, әмма әйтелешләрендә аерма булган сүзләр: *карта – карта*.

4) Омоформалар – билгеле бер грамматик формаларда гына омоним булып килгән сүзләр: *бүлмә(исем) – бүлмә (боерык фигыль).*

**10. Биремнәр.**

1.Текстны укыгыз, эчтәлеген сөйләгез.

2. Иң әһәмиятле 7 җөмләне сорау җөмләләргә әйләндерегез һәм төркемдәшегездән итервью алырга әзерләнегез.

3. Калын хәрефле сүзләргә игътибар итегез. Аларга аваздаш сүзләрне табыгыз һәм мәгънәләрен җәяләр эчендә күрсәтеп, дәфтәрегезгә парлап язып төшегез.

Бурсык – **бик** сак җәнлек. Ауга төнлә генә чыга. Шуңа күрә җәй көне куе урман эчендә текә калкулыкта бурсык өнен очратсаң да, аның үзен күрүе җиңел түгел. Оясыннан чыкканчы, ул башта сакланып **кына** сузылып карый, тыңлап тора, исни, аз гына шикләнсә дә, яңадан кереп кача. Бурсыкның оясы тирән була. Ул тармакланып күп төрле җир асты юлларыннан тора. Өстәвенә, бурсык ел саен яңа юллар казый. Ул оясында кышлый: күп итеп үлән ташый да шуның белән эчке яктан оя авызын томалый һәм... йокыга тала. Дөрес, бурсыкның йокысы каты булмый, тәненең температурасы төшми. Кайчакта, аеруча көннәр җылыта башлагач, ул, йокысыннан уянып, оясыннан чыга. Гадәттә ул көндез чыга. **Менә** шул чак аны әйбәтләп күзәтергә була. **Бу** – шактый зур, буе 90 см га җитә торган юллар, ә күз һәм колаклары аркылы **кара** юл узган. Йомшак кар өстендә нык тырнаклы тәпи эзләре әйбәт күренә. Шушы тәпиләре белән ул оя казый, җир астыннан үсемлек тамырларын бик җитез генә казып ала, шушы көчле тәпиләрен аңа дошманнарыннан саклану өчен дә хезмәт итә. Бурсык үзе - тыныч җәнлек, башлап беркемгә дә ташланмый. Кар өстендә бераз йөреп алгач, бурсык яңадан йокларга кайта. **Яз** көне, оясыннан чыгуга **ук**, эшкә тотына. Иң элек бик әйбәтләп ашап ала: кыш буена бик ябыккан була, аннары ояда аска җәелгән үләнне алыштыра яисә яңа оя казый. Менә бурсык балалары дөньяга килә. Гадәттә аларда өчәр, бишәр бала була. Ана бурсык аларны бик тырышып карый, күзләре ачылмаган балаларын көн саен кояшка алып чыга. **Ә ата** бурсык ояны бик

әйбәтләп чистарта, аска җәелгән үләнне җәй буена берничә тапкыр алыштыра.

Күзгә **таба** бурсыклар гаиләсе **май** туплый башлый – кышка әзерләнә. Карап торышка авыр сөякле булып күренгән бурсык кимерүчеләрне, бакаларны, кәлтәләрне бик оста аулый, суалчан казып ашый. Алар, май коңгызы личинкаларын бик күпләп юк иткәнгә, аеруча файдалы.

**бурсык – барсук**
**кимерүчеләр – грызуны**
**тармакланып киткән – разветвленный**
**ташланмый – не бросается**
**туплый - скапливает**
**тәпи - лапа**
**карап торышка – на первый взгляд**
**күзәтергә - наблюдать**
**шикләнсә – если сомневается**
**аулый - охотится**
**өн - нора**
**коңгыз – жук**

**11. Биремнәр.**
1. Текстны укыгыз һәм нинди хайван икәнен ачыклагыз.
2. Текстны язмача тәрҗемә итегез.
2. Түбәндәге сүзләрнең омонимнарын текстан эзләп табыгыз һәм дәфтәрегезгә язып куегыз: ат (фигыль) - ................., буй (рост) - .........., кара (фигыль). -......, ак (фигыль) - ..........., йөз (исем, фигыль) - ..............

По внешнему облику ......... легок, строен, высоконог. Однако голова у него относительно тяжелая и уши длиннее, чем у лошади, хотя гораздо короче ослиных. Хвост короткий, с черно-бурой кистью на конце, как у ослов и зебр. Окраска ............ песчано-желтого цвета различных оттенков и насыщенности (у животных разных подвидов). Брюхо и внутренние части ног белые. От холки до крупа и далее по хвосту идет узкая черно-бурая полоса. Грива невысокая, стоячая, черно-бурая, протягивается от ушей до холки. Длина тела 200-220 см, высота в холке 110-137 см, масса - 120-127 кг.

**Бу кызык!**

**Арыслан “лев”** сүзенең ясалышы буенча ике төрле аңлатма бар:
1) арсыл + аң, ягъни “саргылт хайван”(арсыл – “ саргылт”+ аң – “киек”);
2) арыс+лан, ягъни “ярсу җанвар”(арыс – комсыз, ярсу + лаң – җәнлек, җанвар).

**Җанвар** “зверь, существо» - фарсы җаноwар “җан иясе, җан йөртүче”.

**Җәнлек(киек)** “зверь” – бор. төрки. *җанлыг* “җанлы нәрсә(кемсә), җан иясе” сүзеннән.

**Куян** “заяц” – гом төрки *куйан, койан*, борынгы гомумтөрки *корган, коргун* “куян” сүзеннән, *кор* – “курку”. Тува телендә *койгун* “куян”, *кой* – “курку” дигәнне аңлата.

**12. Биремнәр.**

1.Шәүкәт Галиевнең “Куян” шигырен сәнгатьле итеп укыгыз. Куян һәм арыслан сүзләре нинди мәгънәләрдә кулланылганнар?

2.Кыр һәм йорт куяны турында диалог төзегез.

Артында – Казан,
Алдында – Ослан
Иделне кичеп,
Кайта Арыслан.

Кайта ул посып –.
Алмаган билет.
Малайны күрә
Контролер килеп.

Бу абыйларда
Тәртип бик каты:
-Кайда яшисең?
Үзең ни атлы?

Авылым, әнә -
Югары Ослан...
Әтием – Габбас,
Үзем – Арыслан.

Ачулы абый
Елмаеп куйган:
Юк инде, дигән,
Бүген син “куян!”

(Шәүкәт Галиев).

**13. Биремнәр.**

1. Текстны тәрҗемә итегез.
2.Текст буенча татарча алты сорау әзерләгез һәм җаваплары белән дәфтәрләрегезгә язып куегыз.
3. Әлеге җанвар турында тулырак мәгълүмат туплагыз һәм татарча монолог сөйләргә әзерләнегез.

**...............**деятелны и днем и ночью, пасутся охотнее всего утром и вечером, иногда даже ночью. Пищу их составляют различные травы, листья, почки и кора деревьев. Их любимое дерево, кажется, ясень, сочную кору которого они предпочитают всем другим; хвойные деревья, не трогают. Зимой едят почти исключительно кору и ветки доступных им лиственных деревьев, кроме того, лишайники и сухую траву. Они могут прыгать до 3 м в длину и до 2 м в высоту. Ареал ...........в средние века охватывал Центральную и Восточную Европу от Германии и Венгрии до бассейна Дона и Кавказа.

**14. Биремнәр.**

1. Текст ахырындагы сүз һәм сүзтезмәләрне куеп, текстны укыгыз.
2.Әлеге җәнлекнең исеме Татарстандагы бер елга исеме белән аваздаш. Нинди елга бу һәм аның татарча исеме ничек яңгырый?
3.Текст буенча бер-берегезгә сораулар бирегез.
4. Асларына сызылган сүзләрнең антонимнарын табыгыз. Алар белән текстның эчтәлегенә туры килерлек итеп сорау җөмләләр төзегез.

Кама - буе 70 см га җитә торган сыгылма гәүдәле .................. Каманың тереклек итүе су белән ......................... Ул суда сизгер, житез. ........................... суда ук ашап бетерә. .................. янына, аркасына әйләнеп, ............... һәм аны ярга өстерәп чыгара.

Ләкин, кама туктап сайланган урынны тапканга карап, аның үзен күрүе <u>кыен</u> әле. Ул ................ яр буендагы оясында .............., ә ауга, гадәттә, ..................... Бер сулыктан икенче сулыкка күчкәндә генә, кама ......................................................., аннан, елына бер тапкыр, балалары дөньяга килер вакыт җиткәч, ана кама судан ........................................ оя ясый.

Кама – ................ ул. Иң ................. та аннан котыла алмас иде. Ләкин кама (вакыт рәвеше) да җитез балык <u>артыннан</u> .............. бәлки аннан качып китә алмаган балыкларны тота. Күбесенчә, ........................була. Кама, беренче чиратта, шундый балыкларны ашый һәм йогышка таралырга ирек бирми. Аны су санитары дияргә мөмкин.

**Терәк сүзләр**: *хәйләкәр аучы, һәрвакытта кумый, бик яхшы йөзә, төнлә чыга, оста чума, вак балыкны, астан йөзеп килә, көндез утыра, озынча хайван, шактый озак бара, җитез балык, авыру балыклар, бик нык бәйләнгән, эре балык, ераккарак китеп*.

**15. Биремнәр.**

1. Шәүкәт Галиевнең “Дөя һәм Көя” шигырен сәнгатьле итеп укыгыз. Эчтәлеге турында фикерләрегез белән уртаклашыгыз.

2.Бер аваз белән генә аерылып торган **дөя** һәм **көя** сүзләренә игътибар итегез. Биологик атамалар арасыннан тагын шундый очракларга мисаллар эзләгез (*чукыр – клёст – тукыр - ткач, ас – горнастай – ат – лошадь, эт – собака* һ.б.ш.). Аларны омонимнар белән бутамагыз. Омонимнарның аваз төзелешләре бердәй була. Мәсәлән, *киви “бескрыл”* һәм *киви “тропик үсемлек”* – омонимнар.

3. Калын хәрефле сүзләрнең омонимнарын табыгыз һәм алар белән җөмләләр төзегез.

Барысы да белгәннәр
Тау хәтле Дөяне
Берсе дә күрмәгән
Дөядә Көяне.

Дөя **бит** гел эштә,
Гел юлда, йөк ташый.
Ә көяз Көяме –
Дөяне ул ашый.

Дөяне – Көяме?!
Сөйләмә, **кит** әле,
Берсе – тау, берсе тик
Күбәләк бит **әле**!

Сиздерми **төш**кән дә,
Кискән шул гамьсезне,
Аңа бит барыбер –
Тәмлеме, тәмсезме...

Шулай да бер көнне
**Көя**ләр киткәннәр.
Бетте бит әкият!
Дөя дә беткән лә...
Вәссәлам!

(Шәүкәт Галиев).

**16.Биремнәр.**

1. Имезүчеләрнең атамаларын игътибар белән карагыз, бер генә авазны үзгәртеп алардан төрле сүзләр ясагыз. Мәсәлән, аю – ай, ак, ас – “горнастай”, ач, ат һ.б. *Тиен, бүре, ас, фил, байбак, як, болан, әрлән, кама, кәлтә, актеш, каплан, коала, колан, ишәк, кит , поши, төлке.*

3.Түбәндәге сүзләрнең омонимнарын табыгыз, аларның икесе белән дә җөмләләр төзегез. *Тиен, каплан, актеш, ас, кит, кушаяк, як.*

## §4.Татар телендә күчерелмә мәгънәле тотрыклы сүзтезмәләр


**Укыгыз һәм истә калдырыгыз!**

Фразеология (грек. phrasis – тәгъбир, logos – сүз, тәгълимат) термины ике мәгънәдә кулланыла: 1) тел белеменең фразеологик берәмлекләрне өйрәнә торган бүлеге; 2) телнең фразеологик берәмлекләр җыелмасы.

Фразеологизм ул, асылда бербөтен мәгънә белдерүче, чынбарлыктагы күренешләрне тәэсирле, сурәтле һәм сәнгатьле итеп чагылдыручы семантик һәм синтаксик яктан таркалмый торган тотрыклы сүз тезмәсе. Мәсәлән: *күңел тулу, күңел ярасы, баш күккә тию, ачык авыз* h.б. Тикшерүчеләр, гадәттә, аларны сөйләмдә әзер килеш саклануын, семантик яктан бөтен, грамматик яктан таркалмавын күрсәтәләр, сурәтлелек ягына аеруча басым ясыйлар. Дөрестән дә, фразеологизмнар – телнең сурәтләү чаралары. Ә сурәтлелекнең нигезендә бер предметны икенчесенә, бер күренешне икенче предметка чагыштыру тиңләү ята. Фразеологизмнарның мәгънәләре дә, формалары да күп төрле.

**17.Биремнәр.**

1. Югарыдагы рәсемнәргә карагыз, әлеге имезүчеләрнең татарча-русча атамаларын әйтегез. Алар белән бәйле нинди фразеологизмнарны беләсез. Шул турыда фикер алышыгыз.
2. Рәсем буенча диалоглар төзегез.
3. Рәсемдәге хайваннарның берсе турында татарча презентация ясагыз һәм аны сөйләргә әзерләнегез.




**Бу кызык!**

**Сыртлан.** Сырт + лан, ягъни “сыртлы буй-буйлы хайван” (сырт “сырт, арка”+ лаң – “җәнлек”). Башкорт телендә сыртак, һыртак - “аркасы тасмалы хайван”.
**Керпе**. “Кэрпиг” – борынгы төрки телдән “энәле, энәлек” сүзен аңлаткан.“Кырп, кэрп” – “энә кадагыч” тамырыннан.
**Юлбарыс.** Гомум төрки телдә йолбарс “юлбарыс” – юллы барыс – “полосатый барыс” сүзеннән.

**18. Биремнәр.**

1. Фразеологизмнарның мәгънәләрен икенче баганадан эзләп табыгыз һәм дәфтәрләрегезгә күчереп языгыз.
2. Киек-җанвар атамалары кергән 10 фразеологизм язып алып килегез.

| **Фразеологизм** | **Туры мәгънәсе** |
|---|---|
| Куян койрыгы тоттыру | Берәр ихтималдан куркып, шикләнеп эшләмичә тору |
| Куян урынына зыян | Үзенең чын хәлен кешедән яшерүгә карата |
| Куян җанлы | Юкны вәгъдә итеп алдау |
| Арыслан йөрәк | Кечкенә генә яра-җәрәхәткә дә чыдамаган кешегә карата |
| Аю хезмәте күрсәтү | Ишектән бер кереп, бер чыгып йөрүчегә карата |
| Аю ботына шырпы кадалу | Файда китерәм дип, зыян салу |
| Бүредән куркып урманга бармау | Куркак кешегә карата |
| Керпе кебек йонын тырпайту | Яхшылык эшлим дип зыян салу |
| Керпе аягын күрсәтмәгән күк | Көчле, курку белмәс, гайрәтле |
| Куян аягы ашаган | Теше-тырнагы белән каршы тору |

**19.Биремнәр.**

1. Түбәндәге фразеологизмнарны укыгыз, аларны нинди очракларда кулланалар? Бу фразеологизмнарны үзегезнең сөйләмегездә кулланганыгыз бармы? Төркемдәшләрегез белән шул турыда фикер алышыгыз.
2. Нәкый Исәнбәтнең “Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге”ннән имезүчеләр белән бәйле һәм сезгә таныш булмаган 5 фразеологизмны язып алып килегез.

*Эткә печән ашату; эт муенына энҗе муенса; эт күрмәгәнне күрү; эткә салсаң, эт ашамас; эттән алып эткә салу; эт урынына да күрмәү; эттән эт, беттән бет туа; дуңгызны кондыз итеп булмый; дөядән энә саплату; мәчесе дә куян тоту.*

**20. Биремнәр.**

1. Текстны укыгыз һәм эчтәлеген 5-6 җөмлә белән сөйләргә әзерләнегез.
2. Сез нинди тыюлыкларны беләсез? Шул турыда фикер алышыгыз.
3. Асларына сызылган сүзләр арасында барысы да имезүче хайван атамаларымы? Берсе турында диалог төзеп сөйләгез.

Тыюлыклар – табигатьтәге фәнни лаборатория. Галимнәр анда табигатьнең катлаулы законнарын тикшерә. Һәр тыюлыкта аерым игътибар биреп саклана торган бик тә кыйммәтле нәрсәләр бар. Мәсәлән, Кандалакша тыюлыгында кошлар базары һәм гага оялары саклана. Бу кошның мамыгы бик кыйммәт йөри. Байкал күле буенда урнашкан Баргузин тыюлыгы- кешне саклый торган төп урын. Беловежа урманында тояклы хайваннардан болан, кабан, кыр кәҗәләре күп. Монда кыргый үгезләр, ягъни зубрлар иректә яши. Воронеж тыюлыгында кондызларны саклап калырга һәм үрчетергә мөмкинлек туган. Европадагы кеше аягы басмаган иң соңгы кылганлы даланы, анда яшәүчеләре белән бергә, Украина далаларындагы Аскания-Нова тыюлыгында күрергә була.

# 4.ТАТАР ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ

# ТАТАРСКОЕ УСТНОЕ НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО

**Укыгыз һәм истә калдырыгыз!**

Һәр халыкның гаҗәп дәрәҗәдә бай хәзинәсе – ул халык авыз иҗаты әсәрләре. Татар халкының тормышын зур тарихи вакыйгалардан һәм дан казанган батырлардан, дастан, әкият, бәет, мәкаль-әйтем һәм җыр-биюләрдән, иҗтимагый бәйрәмнәрдән һәм милли йолалардан башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Аларда халыкның әхлакый идеаллары, хезмәт сөючәнлеге, өлкәннәргә ихтирам, әдәплелек, дуслык, туган илгә булган чиксез мәхәббәте, дәреслек, сафлык кебек сыйфатлары чагылыш тапкан.

Нәрсә соң ул халык авыз иҗаты? Телдә бит әле халык әдәбияты, фольклор кебек сүзләр дә бар. Татар энциклопедия сүзлегендә фольклор төшенчәсе түбәндәгечә аңлатыла: “Фольклор – (ингл. folklore), халык тарафыннан иҗат ителгән һәм халык арасында киң таралган әдәбият һәм сәнгать әсәрләре. Татар фольклоры нигездә өч төркемгә бүленә: халык авыз иҗаты әсәрләре (халыкның поэтик иҗаты), музыкаль иҗаты, халык биюләре. Халык поэтик иҗатына мифлар һәм мифологик хикәятләр, легендалар, риваятьләр һәм дастаннар, әкиятләрнең барлык жанрдагы төрләре, мәзәкләр, афористик жанрлар(мәкальләр, әйтемнәр, табышмаклар, сынамышлар һ.б.) керә, лиро-эпик фольклорны мөнәҗәтләр, бәетләр, тарихи җырлар, халык лирикасы, йола, уен, кыска һәм озын җырлар тәшкил итә”[1]

Халык авыз иҗатының үсемлекләр, кош-кортлар һәм киек-җанварлар белән бәйле булган кайбер жанрлары белән танышыйк.

## §1. Легендалар

**Укыгыз һәм истә калдырыгыз!**

**Легенда-** ул нигезендә фантастик күзаллау яткан, могҗизалыкка корылган халык хикәясе. Дөрес, фантазия, уйдырма күп кенә әкиятләргә дә хас, әмма алардан аермалы буларак, легендалардагы хыялый вакыйгалар тормышта чыннан да булган хәл төсле итеп сөйләнәләр

Татар легендаларының тематикасы шактый бай. Аларны күк җисемнәре, үсемлекләр, кошлар, хайваннар, җир астына күмелгән тылсымлы хәзинәләр, шулай ук тарихи вакыйгалар, күренекле шәхесләр турындагы әсәрләргә аерып карарга мөмкин.

Үсемлекләр һәм хайваннарга караган легендалар: “Ни өчен ни булган?” – дигән сорауга җавап эзлиләр. Аларның сюжетлары төрле кошлар, хайваннар, үләннәр, агачлар һ.б. ларның барлыкка килүен, аларга хас булган төрле үзенчәлекләренең җирлеген аңлатуга корылган.

**1.Биремнәр.**

1.Легенданы сәнгатьле итеп укыгыз.

2.Тексттан алмашлыкларны язып алыгыз, төрләрен ачыклагыз.

3.Сезнең әлеге легенданы ишеткәнегез булдымы? Тагын нинди легендалар беләсез? Шул турыда әңгәмә корыгыз.

4.“Усак яфраклары”дигән легенданы табып укыгыз, эчтәлеген сөйләргә әзерләнегез.

**Ни өчен чыршылар һәвакыт яшел һәм матур**

Борын-борын заманда, моннан бик күп еллар элек, җир йөзендә бик матур кешеләр яшәгән. Алар һәрвакыт шат, таза булганнар. Ләкин аларның башына бик авыр кайгы килгән: кешеләр үлә башлаганнар. Яшь балалар да, таза, көчле ир кешеләр дә үлә башлаганнар. Кешеләр бу афәттән ничек котылырга да белмәгәннәр. Бу вакытта кешеләр

[1] Татар энциклопедия сүзлеге. - Казан: татар энцикопедия институты, 2002. – Б. 709.

арасында бик батыр егет яшәгән. Ул халыкның кайгы-хәсрәтенә карап түзеп тора алмаган. Ата-анасының фатихасын алган да тереклек суы эзләп чыгып киткән. Ай киткән, ел киткән, бик озын юллар, кара урманнар, биек таулар үткән, киң диңгезләр кичкән. Шулай йөри торгач, ул бер иркен сахрага килеп чыккан.. Бу Дию пәриенең патшалыгы икән. Йөри торгач, бу бер матур сарай күргән. Егет туры сарайга карап юл тоткан. Аны анда бик гүзәл кыз каршы алган. Бу –Дию пәриендә тоткынлыкта яшәүче кыз икән. Ул егеткә:

-Тиз генә кит моннан, - дип ялына башлаган. – Дию пәрие кайтса, икебезне дә харап итәр, - ди икән. Егет үзенең нинди эш белән йөрүен сөйләгән:

- Сусыз мин бер кая да китмим, - дигән.

Кыз моны бер чишмә буена алып барган. Чишмәнең тирә-ягы яшел үләннәр, матур чәчәкләр белән бизәлгән, агачларда кошлар сайрый икән. Бу тереклек чишмәсе була. Егет савытын тутырып су ала да, кыз белән саубуллашып, юлга чыга. Кыз, аерылганда, моңа көзге белән кайрак бирә. Алар тылсымлы көчкә ия икәннәр Азмы-күпме юл үтә бу, хүзер сизә башлый: Дию пәрие моны куа чыккан. Менә ул килеп тә җитә, менә-менә тотып та алыр. Егет шул вакыт, артына борылып, көзге ташлый, бу урында зур диңгез хасил була. Дию пәрие диңгездән чыкканчы байтак вакыт үтә, егет күп кенә юл ала. Дию пәрие тагын да куып җитә, егет, тагын артына борылып, кайрак ташлый. Һәм ике арада биек тау хасил була. Егет тагын хәтсез юл ала, кешеләр кешеләр янына да кайтып җитәргә ерак түгел инде хәзер. Ләкин Дию пәрие тагын куып җитә. Егет Дию пәрие белән алыша башлый. Бик күп агачларны сындырып бетерәләр. Менә Дию кылычы белән егетнең кулына суга. Егет кулындагы савыт төшеп ватыла, ә суы чыршылар өстенә түгелә. Менә шуннан инде чыршылар мәңге яшел, матур булып калалар.

**2.Биремнәр.**

1. Татар халык легендасы белән танышыгыз. Кошлар турында тагын нинди легендалар ишеткәнегез бар?
2. Кош исемнәренең килеп чыгышы турындагы фикер белән килешәсезме?
3. Төркемдә “Легенданы иң оста сөйләүче” исемле конкурс үткәрегез.
4. Калын хәрефләр белән бирелгән кошларның икесе турында диалог төзегез.

**Кош исемнәре**

Борын-борын заманда, әле җир өстендә кешеләр бөтенләй юк вакытта, дөньяда яшәүче кошларның берсенең дә исеме булмаган, ди. Кешеләр яши башлагач кына, кошларны бер-берсеннән аерып йөртү өчен, аларның авазларына карап, исем кушканнар, ди

**Карга** дигән сүз – “кар-р-р, кар-р-р” дип кычкырудан, **торна** дигән сүз “тор-рыйк, тор-рыйк” дип торкылдаудан килеп чыккан , ди.

Ә менә сыерчык, тартар һәм бытбылдыкка исемнәр алынуы бигрәк тә кызыклы булган. Бик күп еллар элек, бер-береннән артык зур гәүдә аермалары булмаган уртачарак зурлыктагы өч кош, бергә яшәп, бергә көн иткәннәр, ди. Тормышлары алай начар булмаган, бергә тапканнар, бергә бетергәннәр, ди. Сайрашып та җырлашып дигәндәй, көн үткәргәннәр. Өчесенә бер сыерлары булган хуҗалыкларында, шуны савып сөтен эчкәннәр, ләкин сөттән башка һич тә тора алмаганнар.

Бу кошчыкларның бәхетсезлекләренә каршы, беркөнне сыерлары югалган, эзләп-эзләп тә таба алмаганнар. Шуннан нишләсеннәр, башка чара булмагач, актык тиеннәрен җыеп, базарга яңа сыер алырга киткәннәр. Болар, яхшы гына сыер алып, кайтырга дип юлга чыкканнар. Кошларның берсе – сыерның мөгезенә, икенчесе – сыртына, өченчесе койрыкка кунганнар, ди.

“Бер бәхетсез - гел бәхетсез” дигәндәй, болар шул рәвештә сыер өстендә сайрашып, кырларны яңгыратып кайтып барганда, сыерлары-ниләре белән сазлыкка кереп баталар. Шуннан соң нишләргә? Мөгезгә утырган кош:

- Сыер, чык! Сыер, чык! Сыер, чык! – дип кычкыра башлый. Шул арада, сыер чыгарга дип тыпырчына башлау белән, койрык өстендә утырган кош:

-Тар-там, тар-там, тар-там, - дип ялгап җибәрә. Ләкин сыер кузгалган саен бата гына бара һәм ахырда бөтенләй сазлыкка чума. Шуннан сыртка кунган кош:

- Юк бул-дык, юк бул-дык, юк бул-дык! – ди дә, кошлар һавага күтәрелеп, өчесе өч якка очып китәләр. Шуннан бу кошларның беренчесен – **сыерчык**, икенчесен – **тартар** һәм өченчесен **бытбылдык** дип атап йөртә башлаганнар, ди.

**3.Биремнәр.**

1. "Кәккүк каян барлыкка килгән?" дигән легенданы сәнгатьле итеп укыгыз.
2. Легенданың эчтәлегендә кәккүккә хас сыйфатлар бармы? Әлеге кош турында тагын ниләр беләсез? Кәккүк исемле кошның тагын күке дигән атамасы да бар, сезгә кайсы күбрәк ошый һәм ни өчен? Фикер алышуга әзерләнегез.
3. Сезнең *күке төкереге, күке җан* кебек гыйбарәләрне ишеткәнегез бармы, аларны нинди очракта кулланалар?
4. Кәккүк турында монолог языгыз.

Ике кызның әниләре чирләп ята икән. Әтиләре намазга киткәч, бу кызлар кычкырышып, шау-гөр килеп уйнаганнар да уйнаганнар. Әниләре:

-Кызым, су бирегезче, - дип тилмереп су сораса да, бу балалар ишетмәгәннәр икән. Шулай итеп ята торгач әниләре: И Ходаем, кәккүк булсамчы", - диюе булган – кәккүккә әверелеп очып йөри башлаган. Бу балалар, әниләренең кошка әверелеп очып йөрүен күреп:

-Әнкәем, мә, су бирәбез, - дип елаша башлаганнар. Әтиләре намаздан кайтып ишек ачуга - әниләре очып чыгып та киткән. Ике кыз аның артыннан су тотып йөгергәннәр. Чытырманлыклар, таулар үткәннәр. Елый-елый йөгергәннәр. Боларның күз яше тамган җирдән чылтырап чишмәләр агып киткән, аяк табаннары канап, үләннәргә тамган. Яланда кызыл яфраклар очратканыгыз бармы? Менә шул яфраклар аларның каннары тамганлыктан шулай кызарып калганнар, ди. Шуңа күрә кәккүк балаларын карамый, йомыркасын чит кош оясына салып китә икән.

## §2.Сынамышлар

**Укыгыз һәм истә калдырыгыз!**

Сынамыш – киләчәктә нинди һава торышы көтелүен һәм ашлык, яшелчә, җиләк-җимеш уңышының ничек булачагын чамалау максатын күздә тоткан афористик жанр. Аларның нигезендә табигать дөньясындагы күптөрле сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре ята.

Прогноз ясау өчен сынамышларда төрле-төрле билгеләр файдаланыла: күк җисемнәренең ничек күренүе; табигать күренешләренең нинди характерда булуы; ел фасыллары, аерым айлар я көннәрнең ничек килүләре; үләннәр, куаклар, агачлардагы төрле үзгәрешләр; хайваннар, кошлар, бөҗәкләрнең үз-үзләрен тотышлары һ.б.

Бу тематик төркемнәр эчендә "тере барометрлар" сынамышларның төгәллегенә шактый зур ышаныч тудыралар. Чөнки хайваннар, кошлар һава торышының якында булачак үзгәрешләренә аеруча сизгерләр. Хәзерге вакытта кешеләр, 600 төрле тереклек иясенең үз-үзен тотышына карап, һава хәлләрен алдан ук билгели алалар. Еш кына бу җитди фәнни нигезгә корыла. Алма-Ата шәһәре сейсмологлары, махсус биологик полигон оештырып, анда тотылучы бурсыклар, еланнар, байбаклар һәм хәтта чәүкәләр ярдәмендә җир тетрәүләрне алдан белеп тору мөмкинлекләрен өйрәнәләр. Япониядә шушы юнәлештә крокодиллар белән тәҗрибәләр үткәрелә. Бу хайваннар, кагыйдә буларак, тыныч яшәргә яраталар. Инде алар үкерә-кычкыра башласалар, кимендә 5-6 сәгатьтән соң 150 км чамасы радиуста җир тетрәү яки вулкан ату ихтимал икән.

**күк җисеме – небесное тело** **шагыйрәнә караш – поэтический взгляд**
**байбак - сурок**
**гәүдәләндерү- мысленно воспроизводить, вообразить, представить**

**4. Биремнәр.**

1.Сынамышларны укыгыз. Асларына сызылган сүзләрнең тамырларын билгеләгез.

2. Сез сынамышларга ышанасызмы? Кошлар турында тагын нинди сынамышлар беләсез? Шул турыда фикер алышыгыз.

3. Сүзтезмәләрне аерып языгыз, төрләрен билгеләгез.

Аккош иртә килсә, яз начар булыр, озак торыр.
Казлар суда чумып-чумып уйнаса, яңгыр була.
Карга җилгә каршы утырып кычкырса, яңгыр булыр.
Акчарлак килгәч, елгаларда боз тиз кузгалыр.
Апрель аеда торна кычкырса, ел яхшы килә.
Карга җилгә каршы утырып кычкырса, яңгыр булыр.
Кечкенә кошлар һавага биек күтәрелсә, аяз булыр.
Тартай, бүдәнә кычкырса, яңгыр булыр.
Тилгән кычкырса, озак аяз булыр.
Торна биесә һава җылы булыр.

**5. Биремнәр.**

1. Сүзләрдән, сынамыш килеп чыгарлык итеп, җөмләләр төзегез.
2. Курсив белән бирелгән сүзләр ярдәмендә диалог төзегез.

Өненә салкын печән-салам *әрлән* күп, кыш ташыса булыр.
Күп көз булса, кыш *тычкан-күсе* килер көне җылы.
Буласы төлке өрер булса, кебек суык эт.
Суык тычканнар, тирән булыр күселәр кыш казыса,ояны.
Җылы килер коймага , ышкынса җәй *ат*.
Ат бу югалса, үлә йөгәне атның.

**6. Биремнәр.**

1. Күпнокталар урынына тиешле кушымчаларны куеп, сынамышларның эчтәлеге белән танышыгыз. Бу кушымчаларның кайсы фигыль төренә каравын искә төшерегез һәм алар турында сөйләргә әзерләнегез.
2. Курсив белән бирелгән сүзләргә капма-каршы булган сүзләр языгыз.
3. Калын хәрефле сүзләргә аваздаш сүзләр табыгыз, фикерегезне дәлилләгез.

Чыпчыклар агач очына кун...лар, *көн* салкын була, *түбән* ботакларына кунсалар, җил *чыга*.
Бытбылдык кычкыр... ел иген була; тартар кычкырса, иген булмый.
**Кара** каргалар ояга утырса, өч атнадан чәчүгә чыг... кирәк.
Кәккүк **яз** көне агачлар яфрак яргач та кычкырса, *ачлык* бул...
Көз чүмәлә янында тычканнар *күп* җыелса, икмәк кыйммәт булыр.
**Күк** күкрәүдән элек торна кычкырса, туклык булыр.
**Кыр** казлары яз көне *биектән* очсалар, сабан ашлыгы **бик** уңар, түбәнтен очсалар, ашлык гадәттәгечә булыр.
Сыерчыклар *иртә* килсә, сабан ашык уңа, соң килсә – арыш уңа.
Сыерчыктан алда тургай килсә, туклык булыр.

## §3. Табышмаклар

**Укыгыз истә калдырыгыз!**

Табышмак, исеменнән аңлашылганча, тыңлаучылар алдына нинди дә булса билгесез бер әйберне яки күренешне эзләп табу бурычын куя. Табышмак – халык иҗатының бик борынгы жанры. Аның килеп чыгуын фольклорчы галимнәр элекке замандагы яшерен тел күренеше белән бәйләп аңлаталар. Татар халык авыз иҗатында бөҗәкләр, сөйрәлүчеләр, җир-су хайваннары, кош-корт, җәнлекләр, йорт хайваннары турында табышмаклар бихисап.

**7. Биремнәр.**

1.Табышмакларның басымнарын куеп, дәфтәрләрегезгә күчереп языгыз, җавапларын табыгыз.

2. Билгене белдерүче сүз төркемнәрен язып алыгыз, алар белән яңа җөмләләр төзегез.

1)Кырда да, урманда да
Кызыл бүрек кигән бер карт утыра.
2)Олысы да, кечесе дә эшләпә кигән.
3)Багана башында ак калач.
4)Бабай мескен картайган эшләпәсе янтайган
5)Бер анага мең бала,
Аларның да күлмәге кара,
Юсаң да агармый – шунысы бәла.

**8. Биремнәр.**

1.Табышмакларны укыгыз, җавабын табыгыз.

2. Яңгырау тартыклардан гына торган сүзләрне бер баганага, саңгыраулардан гына торганнарын икенче баганага язып төшегез.

6) Җәй дә кыш та, яз да, көз дә чәчәк ата бер төстә.
7)Кечкенә генә таш сандык, сандык эченә мал салдык,
Ачкычын табалмагач, капкачын ватып алдык.
8).Иелә, бөгелә, ак мамыгы түгелә , кара күзе күренә.
9)Кызыл төймәсен аскан, каршыма килеп баскан.
10)Кара урман уртасында кызыл әтәч утыра;
Кагына да сугына, канатыннан кан тама.

**9. Биремнәр**.

1. Сүзләрнең басымнарын дөрес куеп, табышмакларны укыгыз, җавабын табыгыз.

2. Табышмаклардан фигыльләрне язып алыгыз, бер-икесен зат-сан белән төрләндерегез.

11)Кыйнамый, сукмый үзе елата.
12)Күмер түгел, ут түгел, тотсаң, кулны пешерә.
13)Бер үлән бар чокырда, аны таный сукыр да.
14)Энәләрен йоткан, юл буена чыккан.
15)Юл буенда тиле: тигәнгә дә тия, тимәгәнгә дә тия.
16)Җаны булмаса да гомер итә
Җәй тун кия, кыш ялангач.
17) Ак киемен кигән яшел чугын элгән.

18)Нинди агач җилсез шаулый?
19)Аю колак, алтын баш, тамыры зәхмәттән аш.
20)Торалар күл каршында койрыклары башында.
21)Су өстендә сары май.

**10. Биремнәр**.

1. Бөртекле культуралар турындагы табышмакларны укыгыз, җавапларын табыгыз.
2. Калын хәрефле сүзләрнең тамырыннан яңа сүзләр ясап карагыз.

22)**Озын**-озын егетләр, **башларында** бүрекләр.
23)Ук, башы алтын чук.
24)Башы утта, аягы суда.
25)Аягында **кара** ката, тәпиендә кызыл оек, яшел күлмәкле, ак яулыклы.
26)**Кырда** бар алачык, алачык эчендә капчык капчык эчендә карчык.
27)Агач, агач саен ботак, ботак саен оя, оя саен күкәй – сигезәр дә тугызар.
28)Башын ашыйлар, тәнен ашлыйлар, тиресен кияләр.

**11. Биремнәр**.

1. Табышмакларның җавапларын табыгыз.
2. Табышмакларның җавабыннан алынган бер яшелчә турында татар телендә презентация әзерләгез.
3. Сыйфатларны ачыклап килгән сүзләре белән язып алыгыз.

29)Чәчәге агачында, алмасы тамырында.
30)Эсселәнгән саен кат-кат тун кия.
31)Кызыл кызы җир эчендә, чәчләре җир өстендә.
32)Үскәндә яфрагын ашыйлар, үсеп җиткәч, тамырын ашыйлар.
33) Кечкенә генә мишәр кызы йөрәгемне көйдерә.
34)Туп түгел – түгәрәк, күсе түгел – койрыклы.
35)Җир астында картыгыз, сакалыннан тартыгыз.
36)Җир астында җиз бүкән.
37)Түгәрәк кенә кызыл йорт, эче тулы корт.
38)Йомры яткан таш күрдем,
Тозсыз пешкән аш күрдем.

## §4. Мәкаль-әйтемнәр

**Укыгыз һәм истә калдырыгыз!**

Мәкаль - тормыштагы төрле гыйбрәтле күренешләрне гомумиләштереп, тапкыр әйтелгән тәгъбир. Мәкаль ул – тормышның һәртөрле җил-давыллары эчендә безне аталарча кайгырткан киңәшчебез. Мәкаль әйткәндә син халкыңнан тел генә алып калмыйсың, акыл-тәҗрибә, белем-хикмәт аласың. Мәкальләр – тел хәзинәсе. Аларда өйрәнелмәгән бик бай сүзлек фонды ята. Ул телчеләр, әдип-шагыйрьләр, матбугат һәм укытучылар өчен бик зур байлык чишмәсе.

**12. Биремнәр**.

1. Мәкаль-әйтемнәрне укыгыз һәм мәгънәләрен аңлатып бирегез.
2.Киләсе дәрескә “Мәкальнең ахырын тап!” бәйгесенә җиде мәкаль язып килегез.
3. Үсемлек атамаларының русча тәрҗемәләрен әйтеп чыгыгыз.
4. Тексттан исемнәрне табып языгыз, калын сузыктан торган ясалма нигезле исемне килеш белән төрләндерегез.

Абага чәчәге ут булыр, атып җиткәнче юк булыр.
Ак алабута ачлык елның үләне.
Аксыргак бар җирдә ат үлмәс,
Андыз бар җирдә ир үлмәс.
Ачлык елны алабута, туклык елны йолкып ута.
Бер дә юктан үлән башы да селкенми.
Быламыттан чәй булыр
Давыл чәчкәсен өзсәң, давыл чыгар..
Мәкнең бер сабагы – дару, бер сабагы – агу.
Сары мәтрүшкә алтмыш төрле авырудан,
Зәңгәр мәтрүшкә җитмеш төрле авырудан дәва.
Тигәнәк арасында үскән чәчәктән саклан.
Уҗиде сәгать суккач, үләннең шифасы тамырга төшә
Әрекмәнем, кызу капса- яулыгым, баш авыртса – саулыгым.

**13. Биремнәр.**

1. Рәсем буенча сораулар бирегез.
2. Рәсемдәге кош турында монолог төзегез.
3. Бу кош белән бәйле мәкаль-әйтемнәр һәм фразеологизмнар язып алып килегез.



**14. Биремнәр**.

1. Мәкаль-әйтемнәрнең икенче өлешен табып укыгыз, мәгънәләрен аңлатып бирегез.

| | |
|---|---|
| Төнбоек күзен көндез йомар, | мәк чәчәге үсмәс. |
| Камышлы җир – | камыш шул якка борылыр. |
| Кычыткан сабагында | көмешле җир. |
| Җил кай якка иссә, | бодай урмас. |
| Арпа иккән | йөз яши. |
| Авам-авам дигән агач | кич ачар. |

# ӘДӘБИЯТ


1. Азбука природы: Птицы. - Рус. тат. - тат. русский словарь биологических терминов/ Сост. А.Б.Халидов, В.И.Гаранин. – Казань: Магариф, 2001. – 95 с.
2. Азбука природы: Растения. Грибы. - Рус. тат. - тат. русский словарь биологических терминов/ Сост. А.Б.Халидов, А.С. Казанцева. – Казань: Магариф, 1996. – 112 с.
3. Азбука природы: Млекопитающие. - Рус. тат. - тат. русский словарь биологических терминов/ Сост. А.Б.Халидов, В.И.Гаранин. – Казань: Магариф, 2001. – 119 с.
4. Ай колакланса ни була? Халык афоризмнары. – Казан: Мәгариф, 2002. – 143 б.
5. .Әхмәтьянов Р. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. – Казан: Тат. кит. нәшр., 2001. -272 б.
6. Биологический русско-татарский толковый словарь/ Сост.: Ф.Г.Ситдиков, Р.К. Закиев, А.Б.Халидов. – Казань: Магариф, 1998. – 655 с.
7. Болгар, Казан төшми телләрдән: Риваятьләр һәм легендалар. – Казан: Мәгариф, 2001. – 111 б.
8. Брем А.Жизнь животных /Альфред Брем. – М.: Эксмо, 2009. – 960 с.
9. Галиев Ш. Сайланма әсәрләр/Ш.Галиев.5 томда. 3том. – Казан, 2002. – 431 б.
10. Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге: Ике томда. II том. – Казан: Тат. кит.нәшр., 1990. -365 б.
11. Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге: Ике томда. I том. – Казан: Тат. кит.нәшр., 1989. -495 б.
12. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. 3 томда. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1 т., 1959. 239 б.
13. Кем ул? Нәрсә ул? Өч томда. 1 том(А дан З га кадәр). – Казан, 1983, - 354 б.
14.Миргалимова З.Ф. Названия млекопитающих в татарском литературном языке: Автореф. Дис. Канд. филол. наук / З.Ф. Миргалимова. - Казань, 2007. – 22 с.
15.Русско-татарский словарь/ Под ред. Ф.А.Ганиева. – М.: Рус.яз.,1991 .- 736
16. Саберова Г.Г. Название растений в татарском литературном языке/ Г.Г. Саберова. – Казан: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, 1996. -130 с.,
17. Садыкова З.Р. Зоонимическая лексика татарского языка / З.Р.Садыкова. – Казань: ИЯЛИ им Г.Ибрагимова АН РТ, 1994. – 128с.
18. Сафина Э.И. Названия птиц в татарском языке и их лексикография/ Э.И.Сафина. – Казань: Дом печати, 2000. – 160 с.
19. Сафиуллина Ф.С. Антонимнар сүзлеге / Ф.С.Сафиуллина. – Казан: Хәтер, 2005. – 235 б.
20. Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология / Ф.С.Сафиуллина. – Казан: Хәтер, 1999. – 288 б.
21. Сафиуллина Ф.С., Ризванова Л.М. Татар теленең омонимнар сүзлеге. – Казань: Хәтер. – 1997. – 96 б.
22. Сәлахова Р.Р. Татар теленең сүз төзелеше /Р.Р.Сәлахова. – Казан, 2010. – 66 б
23. Татар грамматикасы. 3 томда.Т.1. - М: “Инсан”, Казан: “Фикер”, 1998. - 510 б.
24. Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – 320 б.
25. Татарча-русча сүзлек/Ф.А.Ганиев редакциясендә. – казан, 1995, -462 б.
26. Татар халык иҗаты.Табышмаклар. - Казан: Тат.кит.нәшр., 1977. – 231 б.
27. Хайрутдинова Т.Х. Народные названия растений в татарском языке/ Т.Х. Хайрутдинова. – Казань: Фикер, 2004. -224.с.
28.Халидов Ә.Б. Кызыл китапның яңа басымасы/Ә.Б.Хәлидов. Мәгариф. – 2007. – №9. – Б67-68.
26. Ханбикова Ш.С. Татар телендә синонимнар сүзлеге / Ш.С.Ханбикова. - Казан, 1980. - 208 б.

## Татарча-русча биологик терминнар сүзлекчәсе
## Үсемлек атамалары

Абага – папоротник
Агач гөл – фикус
Аерча – лепесток
Азыктамыр - корнеплод
Айравык – пырей
Айчәчәк- ноготки, календула
Аксыргак – чемерица
Ак чыршы - пихта
Алабута – лебеда
Ала миләүшә – анютины глазки
Алкагөл – фкусия
Андыз - девясил
Арпа – ячмень
Артыш - можжевельник
Әвернә чәчәклеләр – крестоцветные
Әдрәс гөле – бегония
Әлүчә - алыча
Әрекмән – репейник
Әрем – полынь
Әспе – спаржа
Әстерхан чикләвеге – грецкий орех
Әфлисун - апельсин
Бадымҗан баклажан
Бака яфрагы – подорожник
Бакра гөл – петуния
Балавыз агачы - восковик
Балан – калина
Балтырган - борщевик
Башак – соцветие колос
Бәбәнәк – зародыш
Безүлән – шильник
Билчән – осот
Бишьяфрак – сабельник, пятилистник
Борай –полба
Борчак – горох
Борыч – перец
Ботак – сук, сучок, ветка
Бохар кынасы – бальзамин
Бөергән - жирушник
Бөрлегән - ежевика
Буяу матдәсе – пигмент
Бәбрия – розмарин
Бәбәк – побег
Бөергән - жируха
Бөре - почка
Бөтнек мята
Бүлбе - клубень
Бүре җиләге – волчьи ягоды
Гөнҗә – бутон
Гөлбадран – пижма
Гөлчәчәк – роза
Гөлҗимеш - шиповник
Дарчин - корица
Дәлия – георгин
Дәфнә – лавр
Дөге – рис
Дүләнә – боярышник
Дүңкәл – ирга
Җимешлек – плодник, пестик
Җир чикләвеге - арахис
Җитен – лён
Зелпе – жимолость
Зирек – ольха
Зәгъфран - шафран
Зәйтүн - маслина
Зәнҗәбил – имбирь
Имән – дуб
Имән чикләвеге (күркәсе) – желудь
Йөзем - виноград
Кавын - дыня
Казаяк – лютик
Камчау – скабиоза
Канлы үлән – чистотел
Кара җиләк – черника
Карагай - лиственница
Карама - вяз
Карлыган - смородина
Кастор үләне (кәнә уты) – клещевина
Кәстәнә – каштан
Кәүсә – ствол
Киндер – конопля
Кишер – морковь
Келәнчел - пролеска
Корычагач – ясень
Көнбагыш - подсолнух
Кузак – боб
Кузаклылар – бобовые
Кузгалак - шавель
Кызалак – тюльпан
Кына – хна
Кына гөле - базилик
Мәтрүшкә (сары) - зверобой
Мәтрүшкә (зәңгәр) - душица
Меңьяфрак – тысячелистник
Miләш – рябина
Миләүшә – фиалка
Миңгерәткеч - дурман
Мүк җиләге - клюква
Нарат - сосна
Наратбаш – хвощ
Ногыт борчагы – фасоль
Орлык – семя
Өрәңге – клён
Өянке - ива
Песиле тал - верба
Сарут - пырей
Сырлан – липучка
Сәрдә - сныть
Сабак – стрелка
Сазанак – багульник
Саз җиләге - морошка
Сазлавык уты – ситняк болотный
Сарут – пырей
Сарымсак – чеснок
Сәрви агачы - акация
Серкә – пыльца
Солы – овёс
Сусән - тимофеевка
Суүсем – водоросль
Сөмбел - гиацинт
Сөтле билчән – бодяк
Сөтлегән – молочай
Сырганак – облепиха
Тамыразык – корнеплод
Тары - просо
Татлы бәрәңге – батат
Тәлгәш - гроздь
Тереклек тамыры – женьшень

Тереклек шалканы – турнепс
Торма – редька
Торнабаш – аистник цикутный
Торна борчагы - вика
Тукранбаш – клевер
Төлке койрык – лисохвост
Төче чия - черешня
Тузганак - одуванчик
Тәкәмөгез - донник
Түндербаш - болиголов
Тырнак гөл – календула
Умырзая - подснежник
Уралма сабаклылар – вьюнковые
Усак – осина
Үги ана яфрагы – матьи-мачеха
Үренте - рассада
Үсемлек - растение
Үсем – прирост
Үсентне - отросток
Утчәчәк – адонис
Хәтфә гөл – петушиный гребешок
Хөрмә – хурма
Һиндыба – цикорий
Чалмабаш – пион
Чатыр чәчәклеләр – зонтичные
Чикләвек – орех
Чия - вишня
Чормавык – аралия
Чыклы үлән - росянка
Чәкән – початок
Чәчәк ату – цветение
Чөгендер - свекла
Шайтан таягы – чертополох
Шалкан – репа
Шомырт – черёмуха
Шыту – прорастание
Шәфталу – персик
Шөббуй – левкой
Эрбет агачы - кедр
Эт тигәнәге – череда
Эт җиләге(карга җиләге) – паслён
Ябалдаш – крона
Янар чәчәк – горицвет
Яран – герань
Ясмин – жасмин
Ясмык - чечевица

## Гөмбә атамалары

Агач гөмбәсе – трутовик
Ак гөмбә – белый гриб
Ак гөреҗдә – белый груздь
Ал гөмбә – сыроежка
Әтәч гөмбәсе – лисичка
Баллы гөмбә – опёнок
Бөрлегән гөмбә – гриб ежевик
Гади яз гөмбәсе – вешенка обыкновенная
Гөмбә-тамыр – микориза
Гөмбәлек –грибница, мицелий
Дуңгыз гөмбәсе – свинушка
Җирән гөмбә – рыжик
Зәһәр гөмбә – поганка бледная
Йолдызсыман гөмбәләр – звездчатковые грибы
Каен гөмбәсе – подберёзовик
Кара каен гөмбәсе – чага
Кара гөмбә – чернушка
Кара гөреҗдә – подгруздок черный
Кәҗә гөмбәсе - сморчок
Куык гөмбә – гриб дождевик
Кызылкай – краснушка
Күк гөмбә – синяк
Майлы гөмбә – маслёнок
Мүк гөмбәсе – моховик
Нарат гөмбәсе – боровик
Сары гөмбә – желтяк
Сорыкай гөмбә – серушка
Усак гөмбәсе - подосиновик
Чукмарбаш гөмбә – булавица
Шома гөмбә – гладыш
Шыгырдавык гөмбә – скрипица

## Кош атамалары

Акчарлак – чайка
Аккойрык – белохвост
Аккорсак – белохвост
Аккош – лебедь
Ала карга – ворона серая
Бабакош – пеликан
Балашар – медоед
Безкойрык– шилохвостка
Безтомшык– шилоклювка
Боҗыр – рябчик
Бөркет – беркут
Бүдәнә – перепел
Бүрекле песнәк - синица хохлатая
Бутәкә – желудок птицы
Дала торнасы – авдотка
Имәнборын - дубонос
Кара карга - грач
Карлыгач – ласточка
Каурый кою – линька
Кенәри - канарейка
Керәшәләр – стрижи
Кикрик – гребень
Козгын – ворон
Кош баласы – птенец
Көртлек – куропатка
Күгәрчен – голубь
Күке - кукушка
Күркә – индюг
Күчмә кошлар-перелётные птицы
Кылычтомшык-мечеклюв
Кыр казы - дикий гусь
Кыр тавыгы – куропатка
Кыргавыл – фазан
Кыштума - зимородок

Лачын – сокол
Ләкләк – аист
Миләш чыпчыгы – рябинник
Мыгырдавык чыпчыклар – бормотушки
Нәфис аккош – лебедь-кликун
Песнәк – синица
Саескан – сорока
Сары чыпчык – чиж
Солы чыпчыгы- овсянка
Су тавыгы - лысуха
Су чыпчыгы – оляпка
Суер – глухарь
Сызгырак чыпчыклар - свиристели
Сыерчык – скворец
Тавә кошы - страус
Тавис кош – павлин
Тартар – дергач
Томшык – клюв
Торна – журавль
Торымтай – пустыльга
Тукран – дятел
Тукыр – ткач
Тургай – жаворонок
Тутый кош – попугай
Умрау сөяге – ключица
Умыртка – позвоночник
Урман тавыгы – тетерев
Уҗым чыпчыгы – ржанка
Чебенкош – колибри
Чукыр – клёст
Чыпчык – воробей
Чәберчек – трясогузка
Чәүкә – галка
Чүкечбаш – молотоглав
Шоңкар – кречет
Шөлди – кулик
Элпә – перепонка
Ябалак – сова
Ягылбай - кобчик
Ядәч сөяге – дужка, вилочка
Яр карлыгачы (керәшә) – стрижи
Яр чыпчыгы - зимородок
Үрдәк – утка
Үрмәләч – поползнь
Җир чыпчыклары – вьюрки
Һөдһөд - удод

## Имезүчеләр атамалары

Ак дельфин – белуха
Ак төлке – песец
Актеш – белозубка
Арслан – лев
Ас – горастай
Аю – медведь
Әрлән - хомяк
Байбак – сурок
Бурсык – барсук
Бүре - волк
Диңгез дуңгызчыклары – свинки морски
Диңгез мәчесе – котик морской
Дуңгыз – свинья
Ерткыч дельфин – косатка
Жофар – выхухоль
Җанвар – зверь
Җәнлек - зверь
Иренчәк – ленивец
Йорт куяны – кролик
Йомран – суслик
Кама – выдра
Кара каплан - пантера чёрная
Каплан – леопард
Кәҗә боланы – косуля
Керпе - ёж
Кеш - соболь
Колан – кулан
Кондыз – бобр
Кушаяк – тушканчик
Куштояклылар – парнокопытные
Куян - заяц
Кыргый кәҗә – антилопа
Кырмыскаашар – муровьед
Көзән – хорь
Көнгерә – кенгуру
Күсе – крыса
Ләтчә – ласкка
Маймыл - обезьяна
Мөгезборын – носорог
Нәфис болан - лань
Норка – чәшке
Очкалак – летяга
Поши - лось
Саз кондызы – нутрия
Сасы көзән - хорёк
Селәүсен - рысь
Су күсесе - ондатра
Су сыеры – бегемот
Сусар – куница
Сыртлан – гиена
Тиен – белка
Төлке – лиса
Уклы керпе – дикобраз
Үгез - бык
Үрдәкборын - утконос
Фил - слон
Чүл бүресе – шакал
Энәйонлылар – иглошерстые
Юлбарыс – тигр
Янут – енот
Ярканат - летучая мышь
Ярыммаймыл – лемур

ТАБЫШМАКЛАРНЫҢ ҖАВАПЛАРЫ

1,2,3 (гөмбә), 4,5(көнбагыш), 6(чыршы, нарат), 7(чикләвек), 8(шомырт), 9(миләш), 10(балан), 11,12,13(кычыткан), 14(билчән), 15(тигәнәк), 16(агач), 17(каен), 18 (усак), 19(андыз), 20(камыш), 21(төнбоек), 22(кукуруз), 23(бодай), 24(тары), 25(карабодай), 26(солы), 27(борчак), 28(киндер), 29(бәрәңге), 30(кәбестә), 31(кишер), 32(суган), 33(борыч), 34(чөгендер), 35(шалкан), 36(торма), 37(помидор), 38 (кабак).

ЭЧТӘЛЕК

Автордан ……………………………………………………………………3

БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК. ҮСЕМЛЕКЛӘР ДӨНЬЯСЫ

ТАТАР ТЕЛЕНДӘ АВАЗ ТӨЗЕЛЕШЕ....................................................4

§1. Татар язуы тарихы ........................................................................4

§2.Татар телендә сузык авазлар..................................................................5

§3. Татар телендә тартык авазлар ...............................................................6

§4. Татар телендә иҗек төрләре....................................................................8

§5. Татар телендә сүз басымы.....................................................................12

ИКЕНЧЕ БҮЛЕК. КОШЛАР – БЕЗНЕҢ КАНАТЛЫ ДУСЛАРЫБЫЗ

ТАТАР ТЕЛЕНДӘ СҮЗ ТӨЗЕЛЕШЕ....................................................21

§1. Татар телендә тамыр һәм кушымча....................................................21

§2.Татар телендә кушымча төрләре........................................................23

§3. Татар телендә сүзнең нигезе...............................................................24

§4. Татар телендә кушма һәм ясагычлы нигезләр..................................28

ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК. ИМЕЗҮЧЕЛӘР

ТАТАР ТЕЛЕНДӘ СҮЗНЕҢ ЛЕКСИК МӘГЪНӘЛӘРЕ......................31

§1. Татар телендә мәгънәдәш сүзләр........................................................31

§2. Татар телендә капма-каршы мәгънәле сүзләр..................................35

§3. Татар телендә аваздаш сүзләр...........................................................38

§4. Күчерелмә мәгънәле тотрыклы сүзтезмәләр....................................42

ТАТАР ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ...........................................................44

§1. Легендалар.............................................................................................44

§2. Сынамышлар..........................................................................................46

§3. Табышмаклар.........................................................................................48

§4.Мәкаль-әйтемнәр.....................................................................................49

ӘДӘБИЯТ......................................................................................................50

ТАТАРЧА- РУСЧА БИОЛОГИК АТАМАЛАР СҮЗЛЕКЧӘСЕ............51